ТЕЛ ЯШЕРМИК

Укытучылар Миңнеханов һәм Шәймиев белән милли мәгариф турында сөйләште

> 5

ӘТИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР

Баласы булган ир-егетләргә нинди ярдәм каралган?

> 6

ТИРӘН СУ

Ел башыннан бирле Татарстан сулыкларында 17 кешенең гомере өзелгән

> 17

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 92 (28865) | Җомга | 1 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

pixabay.com

УЕНЧЫК УЕН ТҮГЕЛ

ЯШЬЛӘРНЕҢ КИБЕРСПОРТ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЫ АРТА БАРА

Берничә ел элек бу юнәлеш турында әллә ни сөйләмиләр дә иде. Хәзер ул – аерым бер индустрия, фәлсәфә һәм кем өчендер акча эшләү мәйданчыгы да. Киберспорт заман яшьләре тормышының аерылгысыз бер өлешенә әйләнеп бара. Ни өчен аңа сәламәтлеккә зыян сала торган тармак, күңел ачу чарасы буларак кына карарга ярамый? Киберспортның киләчәге һәм бу киләчәктә балаларның нинди мөмкинлекләре бар? Бәйләлек белән чама арасындагы чик кайда?

> 7

Ишетми калмагыз

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов май – июнь айлары буенча губернаторлар рейтингында дүртенче урынны алган. Беренче өч урында – Чечня башлыгы Рамзан Кадыйров, Мәскәү мэры Сергей Собянин һәм Мәскәү өлкәсе губернаторы Андрей Воробьев. Политолог Александр Малькевич фикеренчә, Татарстан Президентының югары күрсәткечләргә ирешүен республиканың илнең иң тотрыклы төбәкләреннән берсе булуы белән аңлата. Шул ук вакытта белгеч Рөстәм Миңнехановның республика халкы өчен һәм илне ныгыту өчен әһәмиятле икътисади бурычларны хәл итүгә әзер булуын әйткән.
Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов март – апрель айлары рейтингында да дүртенче урынны алган иде.

Россиядә корал турындагы законга үзгәрешләр кертелде. Тәэтмәләрне узган ел Казанда булган куркыныч вакыйгадан соң Татарстанның Дәүләт Советы тәкъдим иткән иде. Хәзер корал законда «югары куркыныч чыганагы» дип бәяләнә. Утлы корал алу хокукы 21 яшьтән генә бирелә. Хөкем ителгән кешеләргә лицензия бирү тәртибендә катгый үзгәрешләр бар. Әйтик, исерек килеш йөртү таныклыгын алдырган кеше җәза вакыты тәмамланып бер ел узгач кына корал өчен рөхсәт алуга өметләнә ала. Росгвардиянең Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, республикада 44,5 мең кешенең кулында 75 мең чамасы корал бар. Хокук сакчылары тикшерүләр барышында быел 800 беркетмә төзеп, 240 коралны тартып алган.

Яңа 100 сумлык купюра әйләнешкә кертелде. Россия банкы рәисе урынбасары Белов әйтүенчә, 100 сумлык акча инде 18 ел буе яңартылмаган: соңгы тапкыр аңа 2004 елда үзгәрешләр кертелгән. Яңартуның максаты – саклау дәрәҗәсен яхшырту һәм бизәлешен заманчарак итү. Яңа йөзлек 2017 елда чыгарылган 200 һәм 2000 сумлыклар сериясенең дәвамы булып тора. Төсе элеккечә үк – коңгырт-кызыл. Алгы ягында – курантлар белән Кремльнең Спас манарасы, кире ягында Ржев шәһәрендәге Совет солдатына мемориал сурәте урын алган. Өстәмә саклау өчен өслегенә лак йөгертелгән. Яңа йөз сумлыклар белән бергә искеләре дә чикләүсез йөреячәк. Болары, тузуларына карап, яңаларына алыштырылачак. Яңартылган акча, банкоматлар аңа көйләнгәннән соң, әйләнештә кулланып пайда булачак.

Ял көннәрендә Татарстанда һава торышы яхшыра. Киләсе атна башында температура +27 градуска җитәчәк. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, шимбә-якшәмбе – 2–3 июльдә һава температурасы күтәреләчәк, яңгырлар – урыны белән генә. Көндезге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы +20...+26 күрсәткеченә җитәчәк. Төнлә +7...+12 градус.
Башлангыч фаразларга караганда, киләсе атна башында – 4–5 июльдә явым-төшем көтелми. Дүшәмбе – көндез +20...+25, сишәмбе +22...+27 градус булачак.

Теманың дәвамы 16 нчы биттә>

Районнарда ни хәлләр?

Арча

Район үзәгендәге Дан аллеясында иң яхшы чыгарылыш сыйныф укучылары хөрмәтенә йолдызлар ачу 2009 елдан бирле матур гадәткә керде. Ел саен бирәдә иң сәләтле, тырыш, уңышлары белән сөендереп торучы, олимпиадаларда, фестивальләрдә һәм ярышларда җиңү яулаган һәм призлы урыннар алган чыгарылыш сыйныф укучылары хөрмәтенә яңа йолдызлар кабына. 12 елда Арчаның 1, 2, 3, 6 нчы мәктәпләрен, 5 нче гимназиясен, Түбән Мәтәскә, Ташкичү, Наласа, Лесхоз, Ашытбаш, Иске Чүриле, Курса-Почмак, Яңа Кенәр мәктәпләрен тәмамлаган укучылар исемендәге 30 йолдыз кабынды. Быел мондый хөрмәткә Арчаның 5 нче гимназиясеннән Илзирә Сираҗиева һәм Апаз мәктәбеннән Руфинә Гарипова лаек булды.
(«Татар-информ»)

Зәй

Түбән Камада медицина көллиятен тәмамлаган 5 кыз туган якларына – Зәйгә кайтып эшләячәк. Шәфкать туташы белгечлеге дипломы алган Юлия Ермолаева, Елизавета Мартемьянова, Венера Короноваа, Дарья Викулова һәм Зилә Фәрхетдинова практикаларын да Зәй дәваханәсендә узганнар. «Аларга әле 19–20 яшь кенә, ә эшләре җаваплы. Укыганда да Зәй кызлары үзләрен үрнәк итеп күрсәтте, тырышып укыдылар. Зәйдә практика үткәндә дә алар турында мактау сүзләре килде», – ди кураторлары Эльмира Нәфыйкова.
(«Зәй офыклары»)

Лаеш

Район мөхтәсибәте, Яңа Сокуры бистәсе мәхәлләсе дин кардәшләребезне, барлык татарстанлыларны изге эштә – яңа мәчет төзелешендә катнашырга чакыра. Бирәдә яңа төзелеп килүче коттедж бистәсендә «Мәдинә» исемле яңа гыйбадәтханә салу буенча әзерлек эшләре башланган: мәхәллә оешты, мәчет проекты әзерләнде, гыйбадәтханәне салу өчен җир алынды, подрядчик билгеләнде. Хәзерге вакытта мәчет салыначак урынны әзерләү, җирне тигезләү, коммуналь инфраструктура сузу эшләре алып барыла. Эскиз-проект буенча, яңа мәчет 200 кешегә исәпләнгән, ул ике каттан тора, бинаны хайтек стилендә төзү күздә тотыла. Яңа бистәдә киләчәктә 10 мең кеше яшәр дип көтелә.
(Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте)

Чирмешән

Район мәшгульлек үзәге 76 эш урыны тәкъдим итә. Район оешмалары төрле эшләр башкаручыларга мохтаҗ, бухгалтерларга да вакансияләр бар. Авыл хуҗалыгы предприятиеләренә шулай ук баш агроном, зоотехник, инженер, ветеринария хезмәткәрләре кирәк, психологларга да эш тәкъдим итәләр.
Быелның алты аенда үзәккә 346 кеше мөрәҗәгать иткән, шуларның 85е эш эзләүче буларак исәпкә куелган. Бүген 37 райондашыбыз эшсез булып санала.
(«Безнең Чирмешән»)

ИЮЛЬ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ

Хәрби хезмәткәрләрнең балаларына пособиеләр күләме арта, пенсия тупланмаларын ышанычлы саклау ысулы пәйда була, бурычлылар үз керемнәреннән тотып калуны тыю турында гариза яза ала.

vk.com

Солдат кызы, солдат анасы

1 июльдән, Россия Президенты Владимир Путин боеруы буенча, хатын-кыз хәрби хезмәткәрләр бала карау өчен пособиене калган барлык аналар кебек үк алачак. Погонлы ханымнарга пособиеләрнең максималь күләме мәҗбүри социаль иминиятләштерү системасына кертелгән погонсыз аналар өчен билгеләнгән айлык пособие күләменә җитәчәк. Исегезгә төшерәбез: хәрби хезмәткәрләр социаль иминиятләштерү системасына кертелми һәм шуңа күрә аларның яшь ярымга кадәрге баланы карау өчен пособиесе гадәти аналарныкыннан күпкә ким иде. Менә хәзер әлеге гаделсезлек юкка чыгарыла. Пособие акчасы ике тапкырдан күбрәк артып, 31 мең сум чамасы тәшкил итәчәк.

Акчаны тотып калмаячаклар

Бурычлының яшәү минимумы күләмендәге керемен тотып калудан саклау турында закон тулысынча үз көченә керә. 1 июльдән бурычлы кеше банкка яки башка кредит оешмасына һәр ай саен яшәү минимумы күләмендәге хезмәт хакын яки башка керемен тотып калмау үтенече белән мөрәҗәгать итә алачак. Моңа кадәр суд приставына мөрәҗәгать итеп кенә акчаны саклап калырга мөмкин иде.

Тупланма проценты югалмый

Кешенең пенсия тупланмасын законсыз күчерүдән саклау турында закон үз көченә керде. 1 июльдән акчасы үзләренең ризалыгыннан башка гына Россия Пенсия фондыннан дәүләтнеке булмаган Пенсия фондына (НПФ) яисә бер НПФдан икенчесенә күчерелгән кешеләр бу акчаны кире кайтара алачак.

Эш шунда: һәрбер кеше биш елга бер тапкыр Пенсия фондын алыштырырга мөмкин. Моңа кадәр тегe яки бу кеше бер Пенсия фондыннан икенчесенә киткәндә, тупланма акчасының процентларын суд аша авырлык белән генә алырга мөмкин иде. Яңа законга пенсия тупланмасын инвестицияләүдән килүче процентларны югалтмаудан саклаучы яңа нигезләмә кертелгән.

Тизрәк һәм яхшырак

Паспорт рәсмиләштерү вакыты кими. Хәзер Эчке эшләр министрлыгы органнары кешедән яки Күпфункцияле үзәктән документлар алганнан соң 5 көн эчендә бу эшне башкарып куярга тиеш.

Яшәү урыны буенча теркәү дә гадиләштерелә: әлеге мәсьәләне районның яки шәһәрнең теләсә кайсы теркәү органында хәл итеп булачак.

Паспорт буенча медицина ярдәме

Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе (ОМС) полисларының яңа формасы турында закон үз көченә керә. Аның нигезендә, полислар уникаль символлар ярдәмендә иминиятләштерелгән затларның бердәм регистрына кертеләчәк. Шулай итеп, сәламәтлек саклау системасында «цифр»га күчү кәгазь полис йөртү мәшәкатеннән коткарачак.

2024 елның 1 гыйнварыннан медицина ярдәме алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, полис урынына шәхесне раслаучы документ кына күрсәтергә мөмкин булачак. Яңа туган сабыйларга бу хокук инде быел ук 1 июльдән бирелә. Табибка мөрәҗәгать итү өчен, баланың туу турында таныклыгын гына күрсәтергә кирәк булачак.

Салым хезмәтенә бармаячаклар

Россиянең 4 субъектында – Мәскәүдә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, Татарстанда яңа махсус салым режимын кертү буенча эксперимент башлана. Бу төбәкләрдә теркәлгән оешмалар һәм хосусый эшмәкәрләр салым салуның автоматлаштырылган гади системасын куллана алачак.

Яңалык оешмаларны һәм эшмәкәрләрне табышка салымнан, мөлкәткә салымнан, эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган физик затлар милкенә салымнан азат итә. Алар шулай ук өстәмә кыйммәткә салым (НДС) түләми (Россиягә товарлар кerткәндә НДС түләүдән тыш).

Яңа салым режимы буенча салым органнарына декларация тапшырылмый. Эксперимент 2027 елның 31 декабрендә төгәлләнәчәк.

Өченче сангa кадәр

3 июльдән банкларга карата кредитның процентлардагы тулы бәясен өтердән соң өч урынлы санга кадәрге төгәллек белән күрсәтү таләбе гамәлгә керәчәк. Кредит оешмалары кертемнәр буенча гарантияләнгән минималь ставканы килешүнең беренче битендә күрсәтергә тиеш булачак.

Бергә-бергә төзибез

Янә Казан сайланды. Быелның 5–8 октябрь көннәрендә Татарстан башкаласында чираттагы дөньякүләм чара – сәнәгать төзелеше өлкәсендә II Халыкара һөнәри осталык чемпионаты узачак. Ничек узасы, кемнәр киләсе һәм безгә тиячәк файдасы турында Мәскәүдә узган матбугат очрашуында сөйләделәр.

Чемпионатны оештырырга Казаннан кала Санкт-Петербург, Новосибирск шәһәрләре дә дәгъва кылган. Ахыр чиктә Татарстан башкаласын сайладылар. Оештыру буенча хезмәттәшлек турындагы килешүне Санкт-Петербургта узган халыкара икътисади форумда имзаладылар.

Төзелеш чемпионаты «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә узачак. Чарага 30лап илдән 250 компания вәкилләре чакырылы. Төп максат – сәнәгать төзелеше өлкәсендә Россиянең башка илләр белән мөнәсәбәтләрен ныгыту, көндәшлеккә сәләтен арттыру.

Россия торак һәм төзелеш министрының беренче урынбасары Александр Ломакин сүзләренә караганда, быелгы чемпионатның төп үзенчәлеге – студентлар лигасы булдыру.

– Монда алар өчен сәнәгать өлкәсендәге эре, алдынгы оешмалар, актуаль юнәлешләр белән танышу һәм әлеге зур чарада волонтер буларак катнашу мөмкинлеге тудырылачак. Чемпионатта 16 номинациядә 190нан артык студент катнашачак, – диде ул ТАСС агентлыгында узган очрашуда.

Көзен Казанда төзелеш материаллары җитештерүчеләр, девелоперлар (күчемсез милек объектлары төзү һәм реконструкцияләү, җир активларын үстерү белән шөгыльләнүчеләр), фән эшлеклеләре дә очрашып сөйләшәчәк. Ломакин бу чараны төзелеш өлкәсендә быелгы иң зур вакыйга дип атады.

Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов исә Казанның әлеге чараны уздырырга тулысынча әзер булуын әйтте. «Татарстан башкаласының мондый чараларны уздыруда шактый зур тәҗрибәсе бар. Чемпионатны уздырыр өчен инфраструктура булдырылган. Чарада Татарстанның төзелеш тармагы да актив катнашачак», – диде ул.

КРЕМЛЬДӘН НИ ИШЕТЕЛӘ?

Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова республика өчен көн кадагында торган кайбер сорауларга җавап бирде. Сүз ирекләләр батальоны, Алафузов театрындагы янгын, Энгель Фәттаховның яңа вазыйфасы һәм башкалар турында барды.

Билгеле булганча, Татарстанда «Алга» һәм «Тимер» ирекләләр хәрби батальоны барлыкка килде. Яңалары булырмы? Казан Кремлендә шуңа ачыклык керттеләр.

– «Алга» һәм «Тимер» батальоннары ирекле кешеләрдән төзелде. Минем аңлавымча, аны оештыру теләге белән махсус мөрәҗәгать иттеләр. Республика җитәкчелеге оештырырга кирәк дип өндәп йөрмәде. Бу – күңел кушуы, битараф булмаган кешеләрнең теләге. Яңа батальоннар барлыкка килсә, халык ишетми калмас, – диде Лилия Галимова.

Күптән түгел Алафузов театрында чыккан янгын да тынгы бирми. Биредә «Созвездие – Йолдызлык» хәрәкәте дә урнашкан иде. Төзекләндерү күпмегә төшәчәк?

– Бу – төзекләндерү таләп ителгән корылма гына түгел, ә иң элек, билгеле бер статусы булган объект та. Аңа карата таләпләр дә башка. Төзекләндерү күпмегә чыгачагын Мәдәният министрлыгыннан сорарга кирәк, – диде Лилия Галимова.

Журналистлар Актанышның элеккеге башлыгы Энгель Фәттаховның киләчәге турында да сораштылар. Ул нинди вазыйфада калыр? Лилия Галимова күрәзәчелек белән мавыкмаска кушты. Һәрхәлдә, республикадагы төрле дәрәҗәдәге вазыйфаи билгеләнүләр турында халык белми калмас иде.

ЯРДӘМ БУЛАЧАК

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН ХАЛЫК ГОЗЕРЕН ТЫҢЛАДЫ

Кемгәдер – Россия паспорты, кемгәдер читек кирәк. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партия Рәисе Дмитрий Медведевның иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә халыкның гозерен тыңлады.

tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисенә иң элек Мариуполь шәһәреннән Казанга күченеп кайткан Татьяна Здравкова улы белән мөрәҗәгать итте. Ханым югалган документлар урынына яңасын ясатырга һәм Россия гражданлыгын алырга теләде. Моннан тыш Татьяна Владимировна үз нигезен ташлап киткәннән бирле әнисе белән элемтәгә керә алмыйча җәфалана икән. Ул олы яшьтәге әнисенең бүгенге язмышына чиктән тыш борчыла. Үзе исә улы белән, мәҗбүри күченеп килгән башка кешеләр кебек үк, Казан кунакханәсендә яши.

Фәрит Мөхәммәтшин аңа тиешле министрлыклар һәм ведомстволардан, һичшиксез, ярдәм буласын әйтте. «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» вәкилләре исә Татьяна Здравковага әнисен эзләп табарга булышачак. Хәзерге вакытта Мариупольдә партиянең волонтерлары эшли. «Барлык адреслар буенча йөреп, күршеләр белән аралашачакбыз, барлык исемлекләрне һәм мәгълүматлар базаларын барлаячакбыз, кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларына, гуманитар штабларга бу хакта хәбәр итәчәкбез», – диде Дәүләт Советы депутаты, яшьгвардиячеләрнең республикадагы җитәкчесе Марат Бариев.

Казанның Мәрҗани мәчете каршындагы халык ансамбле вәкиле Наилә Сафиуллинага читек кирәк. Наилә ханым, сәламәтлеге какшаган булса да, иҗат коллективы тормышында актив катнаша икән. Үзешчән артистларга сәхнә киемнәрен үз акчасына сатып алырга, бер өлешен үзләренә тегәргә туры килә. Наилә ханымга Казан халык сәнгате промыселлары техникумы ярдәм күрсәтәчәк, якын арада аңа техникум осталары теккән читек бүләк итәчәкләр.

Биектау районы Семиозерка авыл җирлеге башлыгы Дәүләт Советы Рәисеннән авыл җирлеге көнен үткәрүгә ярдәм итүне сорады. Быел ул 2 июльдә үткәрелә. Фәрит Мөхәммәтшин, халык традицияләрен, һичшиксез, сакларга кирәк, авылга кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтеләчәк, дип өметләндерде.

Кабул итудән соң парламент Рәисе журналистлар белән аралашты. «Иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә мондый очрашулар даими үткәрелеп килә. Бу эш рәвеше үзенең нәтиҗәле булуын раслады. Кешеләр безгә күбрәк ышана, төрле сораулар белән мөрәҗәгать итә башлады. Һәрбер мөрәҗәгатьне карап тикшерелүен һәм, мөмкинлеккә карап, уңай хәл ителүен күзәтеп барам», – диде ул.

Сайлауга әзерләнәләр

Казанда «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк сәяси советы президиумы утырышы узды. Дәүләт Советы Рәисе, партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин үткәргән җыелышта өстәмә сайлауда партиядән депутатлыкка кандидатлар расланды.

11 сентябрьдә буласы өстәмә сайлауда Дәүләт Советы депутаты булу өчен 14 нче Пионер бер мандатлы сайлау округыннан «Стратегик инициативалар үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Дмитрий Анисимов көрәшәчәк. Моңа кадәр ул партия праймеризында җиңү яулаган. «Сезнең кандидатураны хуплаячакбыз. Әмма үзегез дә сезгә күрәшкә актив тәстә кушылырсыз, сайлаучылар белән эшләгез!» – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Президиум утырышында шулай ук көзгә өстәмә сайлауга Татарстанның 32 муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органнары депутатлыгына кандидатлар килештерелде. Электрон платформада (pg.er.ru) узган башлангыч тавыш бирүдә барлыгы 225 кандидат һәм 2300ләп сайлаучы катнашкан.

Моннан тыш партиянең Актаныш җирле бүлеге секретаре вазыйфаларын башкаручы Илшат Вахитовның кандидатурасын килештерделәр. Энгель Фәттаховның вәкаләтләре районда тиешле сайлау үткәрелгәнче туктатып торыла.

Президиум утырышында Фәрит Мөхәммәтшин Украинадан, Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан мәҗбүри күченеп килүчеләргә гуманитар ярдәм җыюда актив катнашучыларга партия рәисе Дмитрий Медведевның рәхмәт хатларын тапшырды. «Барлыгы 4 миллион сум акча җыелды. 200 тоннага якын гуманитар йөк белән 14 фура озатылды. Кешеләребезнең мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга әзер булуы күпне сөйли», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Айдар ШӘЙХИН

САБАНТУЙ / САБАН ТУЕ

Ел саен иң билгеле милли бәйрәмебез тирәсендә бәхәсләр куера. Эчтәлеге, уеннары һәм ярышлары гына түгел, хәтта исеменең язылышы да бәхәсләр өчен менә дигән темага әверелә.

Бер ел элек газетада бу мәсьәләдә гомуми аңлатма биргән идек инде. Кыскача әйткәндә, *«Сабантуй»* сүзе дә, *«Сабан туе»* сүзе дә дөрес: ике вариант та кулланыла ала, икесе дә сүзлекләргә кергән, корпусларда куллану очраклары бихисап.

Шулай да, аңлашыла ки, тарихи яктан Сабан туе сүзе борынгырак, грамматика күзлегеннән мантыйклырак. Әмма кулланылыш ягыннан Сабантуй сүзе активрак кулланыла, нәкъ шушы вариант халыкара сүзгә дә, брендка да әверелде.

Тегесе дөрес яки монысы хаталы дип лингвистик сугышлар оештыруның мәгънәсе юк, әмма бер мәсьәләгә игътибарлы булырга кирәк: бер текст эчендә, китапта яисә бер газета-журналда сүзләрнең берсен генә кулланса лар иде. Бит саен яңача язу редакция сәясәтенең тотрыксызлыгы турында гына сөйли, татар орфографиясен кимсетми.

Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре турындагы кагыйдәләрне дә онытырга ярамый. Бәйрәм атамасы буларак, Сабан туе / Сабантуй – ялгызлык исем, баш хәрефтән языла. Әгәр дә җәй буена бара торган бәйрәмнәр циклын берләштереп атыйсыз икән, *сабантуйлар* дип языгыз.

Тагын күплек турында

Газетаның узган атнадагы санында татар телендә күплек санны куллану белән бәйле хаталарга тукталган идек. Шул теманы дәвам итеп, бу көннәрдә генә күзгә чалынган бер очракка тукталып алыйк әле:

Татарстаннан бер төркем язучылар эшлекле сәфәр белән Якутиягә килде.

Хатаны таптыгызмы? Әгәр дә җөмләдә сүзләрнең урыны башкача булса, күплек санныннан гаеп булмас иде: *язучылар төркеме килде, язучыларның бер төркеме килде. Әмма бер төркем, өч төркем, ике команда* сыман тезмәләрдән соң күплек сан кирәк түгел, чөнки аларның күплеген алдагы сүз күрсәтә. Чагыштыру өчен: *Мин бер чиләк җиләк җыйдым.* Дөрес җөмлә бит? *Бер чиләк җиләкләр җыйдым* дип беркемнең дә әйтәсе килмәс.

ГӘҖИТ / ГАЗЕТА

Вакытлы матбугат басмасының бер төрен аңлата торган төшенчәнең татар телендә сүзлектәгечә дөрес бирелеше – газета. Телебезгә ул шундый формада кергән һәм әдәби вариант буларак шушы язылышы сакланган. Озак аңлатуларга бирелеп торасы юк, бу очракта без эш итә торган принцип бик гади: төп әдәби сүзнең үз урыны бар, рәсми стильдә, рәсми матбугат чараларында һәм шуңа охшаш максат белән иҗат ителгән күпсанлы текстларда сүзлектә беренче булып бирелгән *газета* сүзе кулланылырга тиеш. Бу рәсмилектән тыш очракларда башка сүзләрне кулланырга ярый. Бу очракта *газет, гәзит, гәҗит* вариантларының аермасы юк.

Газета – матбугатның бер төре генә түгел, ул җәмгыять тормышының бер феномены. Көндәлектә бу сүз гаять күп кулланылганга, халык телендә ул йомшаграк, матуррак рәвештә әйтелә башлаган. Бу сүзләрдән баш тартуның яки аларны кулланудан качуның мәгънәсе юк.

Иске татар телендә *газета* һәм *журнал* сүзләре урынына гарәп теленнән кергән *мәҗәллә* (журнал, альманах) һәм *җәридә* (газета, журнал) сүзләре кулланылган. 1990 нчы елларда әлеге сүзләрне дә тергезү омтылышы булды.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Тәрбия

Беркөнне дачада аллея буйлап арлы-бирле йөргәндә, каршыма бер эт килгәне күренде. Кечкенә генә иде ул, токымын белмим, ана үрдәк шикелле алпан-тилпән килеп йөгергән була. Мине күрде дә шып туктады бу. Нәрсә әйтер икән, дигән сымак, артыннан килүче хуҗасына борылып карады. Тегесе дәшми, бернинди ишарә дә ясамый. Эт артына борылып карый-карый миңа таба аксаклап теркелди бирә. Каршыма килеп җитәрәк куркынган кыяфәт белән читкәрәк чыкты. Мин: «Какой ты пугливый!» – дигән булам. Ә ул: «Үзеңне бел!» – дигән сымак шыңшып алды. Күз карашларында мине кызгану галәмәтләре дә чагылып киткәндәй булды. Минем белән тигезләшкәч, хуҗасы: «Таяктан курка ул», – дип куйды.

– Кыйнап тәрбияләдегезме әллә?

– Юк ла, кай җиренә сугасың аның... Шулай да беркөнне кыйнап кайтарганнар иде, тәнендә чыбык эзләре калган иде, шуннан бирле кулына таякмы, чыбыкмы тоткан кешедән шикләнә.

Эт хуҗасы белән бүтән сөйләшеп тормадык. Ә эт күздән югалганчы миңа әллә нишә тапкыр борылып карады. Теле булса, нәрсәләр әйткән булыр иде икән ул? Таякка таянып барганымны күргәч, бераз кызганды микән әллә? Эт – кешенең дусты, диләр, мин дә сиңа «дустым» дип дәшим әле. Менә шул, дустым, минем таяк ул таянып йөрү өчен генә. Тал чыбыгы да, таяк та ашап үсмәдем. Кайчак, бәлки, кирәк тә булгандыр. Малай чакта артык шук идек. Бәлки, шуңа күрә безнең чорда һәркемнең диярлек өендә матчага кыстырылган тал чыбыгы булгандыр да. Бер әйткәнне аңламаган балалар өчен иң үтемле тәрбия чарасы иде ул сыек тал чыбыгы. Дөрес, миңа чыбык эләкмәде, ни дисәң дә, әти – укытучы кеше бит, сүз белән акылга кертүне кулай күрде. Әмма бил каешын ычкындыра башласа, котлар калмый иде. Йомшак җиргә бер-ике мәртәбә тамызганы да булды.

Каты сукмый иде әти, шулай да тимер каптырмалы, матурлык өчендерме, тагын бер-ике җирендә тимер бизәк беркетелгән бил каешы бүген дә күз алдымда. Аның сурәтен бүген дә кәгазьгә төшерә алырмын кебек. Димәк, тәрбиядә күпмедер дәрәҗәдә кулланылган ул каеш. Урысларда «кнутом и пряником» дигән сүзләр бар. «Чыбыркы һәм прәннек тәрбиясе» дигәннәре педагогика фәнендә юк үзе, ә менә тормышта булган, димәк.

Берәм-берәм күз алдыма килереп, санап утырам, чордашларым арасында берәүне дә иркәләп, үчтеки-үчтеки итеп үстермәделәр. Бераз кыен күрмәгән, тал чыбыгы ашамаган малайны без кешегә дә санамый идек. Бүген тәрбия башка шул. Баласына кул күтәргән ата-ананы «за домашнее насилие» җавапка тартырга мөмкиннәр. Мәктәптә баланы эшләтү тыела. Без класс белән чиратлашып мәктәп мичен ягу өчен утын әзерләдек, тәҗрибә участогында эшләдек, тик беребезнең дә укасы коелмады.

Мин балага карата көч куллану, аны мәктәптә авыр эшкә җигү ягында түгел. Тик бәндә баласы һәр нәрсә өчен җавап бирәсен, әшәкелек өчен җәза буласын белеп үссен иде, дип кенә әйтмәкче булам. Һәрнәрсәне үз иркенә куйю гаиләләрне, хәтта дәүләтләрне дә җимерергә мөмкин, дим. Язганнарым саташу булса, гафу итегез.

Ә теге эткә килгәндә, аңа берәү дә тиктомалга китереп сукмагандыр. Аның миңа кызганып каравы да шуңа ишарәдер, бәлки. Әти, мәрхүм: «Улым, тик торган баганага берәү дә китереп сукмый», – дип әйтергә ярата иде. Әгәр арт шәрифләребезгә тал чыбыгы я каеш эләккәләгән икән, димәк, нииндер ярамаган эш эшләгәнбез. Менә шул гына иде.

«ИНДЕКСАЦИЯ» ДИГӘН ТАТЛЫ СҮЗ

ДЕФЛЯЦИЯГӘ МӘДХИЯ УРЫНЫНА

Планета масштабындагы ковид-протестларны бүген бәяләр күтәрелүгә каршы урам хәрәкәтләре алыштыра. Үткән атналарда инфляциянең 9 процентка җитүенә ризасызлык белдереп, Бельгия эшчеләре урамга чыкты. Көнбатышның башка илләрендә дә халыклар йөклап ятмый: социаль яклау таләп итеп, урамнарга чыгалар. Протестларны басуның исә бер генә юлы бар: хезмәт хакларын күтәрү, ягъни индексация.

Пенсиясе берничә йөз сумга артып килү өлкәннәр күңелենә ләззәт бирә, айлык кереме арту бюджеттагыларны да сөендерә. Хөкүмәт хәтта шундый таләп куя: бизнес та даими рәвештә хезмәт хакларын индексацияләргә тиеш. Бюджетка бәйсез эшмәкәрләрнең исә хезмәт хакын арттыруның җиңел бер генә юлы бар: җитештерелгән товарга бәяне күтәрәсең. Индексация дигәндә, сүз бит күбрәк эшләтеп, күбрәк түләү турында түгел, ә бер үк күләмдәге хезмәткә түләүне арттыруны күз алдында да тота. Социаль юнәлеше министрлыклар кулында бизнесны эшләүчегә күбрәк түләтүнең механизмнары бар. Әйтик, «минималь хезмәт хакы» дигән төшенчә. Шуны арттырдыңмы, бизнес минимальдән кимрәк түли алмый. Маховик шулай әйләнә: илдә уртача хезмәт хаклары квартал саен артып тора. Хезмәт хакының артуы хөкүмәтнең финанс блогы өчен дә сөенечле, чөнки зуррак кеременнән зуррак салымнар түләнә. Пенсия фондына взнос та күбрәк керә. Бу исә аңлашыла инде: пенсияләрне индексацияләү мөмкинлеге ача. Хезмәт хаклары түләүнең бу схемасын карасаң, барысы да ал да гөл кебек: тормыш яхшыра дигән иллюзия туа. Бу иллюзия массаларда протест потенциалын юкка чыгара, чөнки киләчәккә матур өметләр уята. Әмма ул өметләр һәрвакытта да «инфляция» дигән диварга килеп бәрелә. Әйтик, ун ел рәттән даими индексацияләнгән хезмәт хакына һәм пенсияләргә без ун ел элек сатып алганга караганда күпкә кимрәк товар сатып ала алабыз. Индексация зуррак булган саен, инфляция куәтлерәк. Бәяләр гадәттә индексация турында игълан итүгә үк үсә башлыйлар. Социологлар моны инфляцион көтү (инфляционные ожидания) нәтиҗәсе дип атыйлар. Чиновниклар моннан бик оста файдалана: индексация турында сүз берничә ай алдан кузгалтыла, кешеләр акча арту өмете белән яшәгәндә, инфляцион көтү тәгәрмәче бәяләрне акрын гына өскә этә һәм бюджет шул рәвешле индексация өчен мая туплый.

1990 нчы елларда, без, ыргылып, базар икътисадына килеп кергән чакта, шундый закон бар иде: бюджеттагыларның хезмәт хакларын квартал саен инфляция күләмендә индексацияләргә. Ул законны без ун елга якын үз җилкәбездә күтәрдек. Сиксәненче еллар торгынлыгында тотрыклы рәвештә кулга ике йөз сум хезмәт хакы алып килгән бәндәләр бик тиз арада мең сум һәм йөз меңләгән сумлык хезмәт хакларына ияләндек. Деноминация (акчаның нульләрен кисү) алдыннан бу фәкыйрегез кулына айга миллион сумга якын хезмәт хакы ала иде. «Айның соңгы көннәре бигрәк тә авыр, аеруча соңгы утыз көне» дигән афоризмны бөтен нечкәлеге белән аңлый идек без, фәкыйрь миллионерлар, ул чакта. Ике меңенче елларда ничектер теге инфляция күләмендә индексация турында закон онытыла төште. Хезмәт хакы арту бәхетен бюджеттагылар берничә елга бер генә татый башлады. Ел саен даими рәвештә пенсияләр генә индексациянә һәм алары да Росстат күрсәткән инфляция дәрәҗәсендә генә иде. Инфляция турында сөйләгәндә, Росстатның бик кысмыр икәнен беләбез бит инде. Әмма даими индексация пенсияләрне арттыра иде барыбер. Шундый вазгыять урнашты: бюджеттагыларның хезмәт хаклары өлкәннәр пенсиясе белән тигезләшә, хәтта кимрәк тә була башлады. Бераз соңга калып, вазгыятьне төзәтергә уйладылар: бюджеттагыларның төбәктәге уртача хезмәт хакына бәйле хезмәт хаклары турында указлар пәйда булды. Индексациянең ул формасы тормышка ашырылып ук бетмәде, билгеле, чөнки федераль бюджет мәсьәләне төбәк бюджетлары өстенә тапшырып, проблемадан җайлы гына котылды. Төбәк бюджетлары исә һәрвакытта да кысыр һәм мәсьәләне акча басу юлы белән хәл итә алмыйлар иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Индексация – финанс наркотигы ул, сызлауны вакытлыча басып тора, әмма ахыр чиктә авырту көчәя генә. Язмада мин шул фикерне дәлилләргә теләгән идем. «Индексация бөтенләй булмаса, тормыш ничек булыр иде?» дигән сорауга 24 февральдән соңгы тормыш җавап бирә. Бәяләрнең март шашынуын онытмадык бит әле. Төзелеш материалларына үткән елгы бәяләр котыруы да истә. Силуанов җитәкчелегендәге хөкүмәтнең финанс блогы үзен бик саран тота килеп туган вазгыятьтә. Пенсияләрне индексацияләү көттереп кенә һәм саран гына тормышка ашырылды. Хезмәт хаклары кемнекедер кимеде, кемнекедер артмандыр да, мөгаен. Әмма тоташ рәвештә базарга инфляция күләмендә акча чыгарып ташлау булмады. Һәм без нәрсә күзәтәбез? Тормыш авырайды, әлбәттә. Ашарга акча җиткерү кыенлаша башлады. Төзелеш турында сүз дә алып барып булмый. Торак базары ихтыяҗның кискен кимүен күрсәтә. Хезмәт хакларының кискен артуына өмет булмау сәбәпле, процент ставкалары төшерүгә карамастан, кешеләр кредит алырга ашыкмыйлар. Нәтиҗәдә төзелеш материалларына бәяләр сизелерлек түбәнәя башлады. Росстат һәм хөкүмәт дефляция турында сүз кузгаттылар. Нәрсә генә дип әйтмәсеннәр, дефляция – уңай күренеш ул. Кризистан чыгуның алшарты – бәяләрнең түбәнәеп тотрыклануы. Инфляция һәм индексация исә – банкирлар тегермәненә су коя торган елгалар гына алар. Һич кенә дә икътисади алгарышка хезмәт итмиләр. Бәяләр төшүнең тагын бер уңай ягы бар: кешеләр исраф итүдән туктый, товар бик кирәк булганда гына алалар. Арзанаю көтелә икән, нигә дип товар җыярга ди әле.

Дефляция нәтиҗәсендә бюджетка акча керү кими, әлбәттә. Тик чишелә торган проблема бу. Бердән, индексация өчен акча кирәк булмаячак, бюджетның башка чыгымнары да арттыруны таләп итмәячәк. Хезмәт хаклары түгел, ә халыкның реаль керемнәре артачак. Бизнес та дефляция шартларында үзен башкача тотарга гадәтләнәчәк. Бәя арттыру хисабына түгел, ә үзкыйммәтне киметү һәм товар әйләнешен яхшырту хисабына гына үсеп булачагына төшенәчәк. Соңгысы сыйфатны яхшыртудан башка була алмый. Димәк, фәнни-техник ярыш өчен акча тотарга туры киләчәк. Хөкүмәт курыккан дефляция менә нинди потенциаль мөмкинлекләр ачачак. Эшмәкәрләр кул астындагы белгечләрдән чын мәгънәсендә квалификация таләп итә башлаячаклар. Хезмәт базарыннан чын белгечләр эзләү башланачак. Яңа шартларда чын талантларны эзләү башланды да инде. Эш бирүчеләр хезмәт базарын бернигә дә ярамаган кандидатлар басудан зарланалар, чөнки нәтиҗәле эш күрсәтә алмаучыларны массакүләм кыскартулар башланган һәм шулар эш эзли. Компетенция юк, ә күккә ашкан хезмәт хаклары сорыйлар, дип әйтә җитәкчеләр. Бизнес беренче тапкыр йөз сәләтсез хезмәткәрне йөз талантка алыштыруның (соңгыларына күбрәк хезмәт хакы түләргә туры килсә дә), икътисади яктан күпкә отышлырак булуын аңлый башлады. 34 хезмәткәрнең 28ен яңага алыштыру нәтиҗәсендә керемнең дүрт тапкыр, табышның җиде тапкыр, уртача хезмәт хакының 35 процентка артуын әйтүче эшмәкәр бар. Икътисад дефляция рельсларына басса, барлык бизнесның талантлар эзләвенә юлыгыр идек. Ихтыяҗ бар икән, тәкъдим барлыкка киләчәк ул. Эшсез калучыларга квалификациясен үстерү белән шөгыльләнергә туры киләчәк. Эштән куылганчы ук, компетенциянe кайгыртуның уңышлы икәнен аңлау туачак. Мәгариф системасына бөтенләй башка таләпләр куелачак. Хезмәт хакы арта икән, индексациядән башка артачак. Нәтиҗәле эш хисабына. Икътисадның инфляциягә һәм индексациягә корылган моделе тупыйкка килеп терәлде бит инде. Мәйданга дефляция чыга икән, аннан курыкмаска, киң юл ачарга, аның потенциалын файдаланырга гына кирәк. Россиягә тарих беренче тапкыр шундый үсеш мөмкинлеге бирә. Ул мөмкинлекне файдаланыр өчен махсус хәрби операция төгәлләнергә, тышкы сәясәт дипломатик җайга салуларга көйләнергә тиеш, билгеле. Арзанлы һәм сыйфатлы товар алдында барлык санкцияләр дә чигенәчәк. Җир шары күләмендә экологик, энергетик, азык-төлек һәм социаль проблемаларны бары тик дефляциядән соң килә торган тотрыклы бәяләр аша гына хәл итеп була. Әмма процент капиталына корылган икътисад моделе безне инфляцияле һәм индексацияле тормыш кысаларында тотарга омтылачак. Без ул моделнең җимерелү стадиясен күзәтәбез әле.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

БУЛДЫРЫП БЕТЕРӘ АЛМЫЙБЫЗ!

КАЗАНДА ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫЛАР

Туган тел укытылмаган бер генә мәктәп тә була алмый! VIII Бөтенроссия татар теле һәм әдәбияты укытучылары съездының пленар утырышында Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әнә шулай дип кистереп әйтте. Рус телендә белем бирә торган мәктәпләрдә татар телендә тәрбия сыйныфлары ачуны исә саламга ябышуга тиңләп: «Үзебезне дә, эти-әниләрне дә алдау – милләтнең тамырына кайнар су кою булмасмы?» – диде. Милли мәгарифтә безнениләр көтә?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Минтимер ага нигә шаккаткан?

Съезд эшендә илнең 27 төбәгеннән татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татар мәктәбе директорлары, төбәкләрдәге татар милли-мәдәни автономия җитәкчеләре һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты вәкилләре – барлыгы 500 делегат катнашты. Дүрт ел элек узган корылтайдан аермалы буларак, быелгысы бурычларның төгәл куелуы һәм эшләгән эшләрнең күләме белән аерылып тора иде. Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин искәртүенчә, шушы вакыт эчендә законнар үзгәргән, милли мәгариф өлкәсенә кагылышлы җитди карарлар кабул ителгән. Чарада Президент Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, шәһәр мэры Илсур Метшинның катнашуы да туган телгә булган мөнәсәбәт турында сөйли. Минтимер Шәймиев хәтта: «Чын күңелемнән әйтәм: бу җыен – минем өчен көтелмәгән хәл», – дип тә куйды. Казан Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтованың чыгышыннан соң да гаҗәпләнде Минтимер ага.

– Чибәр дә булып, хатын-кыз да булып, Казанда шундый эш алып баруы сокландыра. Илсур Рәисович, каян таптыгыз мондый кешене? Татарстаныбызда күптән яшибез, башкаланың әлеге эшләрне болай ук алып барганы юк иде әле, – диде Минтимер Шәймиев.

Гүзәл Сәгыйтова исә чыгышында башкалада тормышка ашырыла торган яңа милли проектлар белән таныштырды. Аның әйтүенчә, татар бакчалары, мәктәпләр эшчәнлеген күзәтеп торалар. Бүген шәһәрдәге бакчаларда татар балаларының 49 проценты ана телендә тәрбия ала. Бик күп нәрсә җитәкчегә бәйле. Аның эшләү теләге булса, ул үз янына иң булдыклыларны җыя яки яшьләрдән менә дигән милли кадрлар әзерли.

Дәүләт Киңәшчесе милләтебезне саклау, бигрәк тә башка төбәкләр белән уртак тел табып эшләүнең нәтиҗәсе барлыгын әйтте. «Җиңел эш түгел, алай була да алмый. Әгәр барыбыз берләшеп, үзара аңлашып эшләсәк, күп нәрсәгә ирешергә мөмкин. Бүгенге очрашу халкыбызның яшәргә омтылышын күрсәтә», – диде Минтимер Шәймиев. Шулай ук узган гасырның туксанынчы елларын искә төшереп: «Аллаһ Тәгалә андый чорны башка күрсәтмәсен иде», – диде.

Сабан туен үзгәртергә кирәк?

Рөстәм Миңнеханов исә сүзен Якутиядә узган Татарстан көннәреннән башлады. «Без үзебезне күп эшлибез, булдырабыз дип саныйбыз, ләкин күп әйберләр буенча эшләргә кирәк әле. Якутларның Сабан туе кебек Ысыах дигән милли бәйрәмнәре бар. Аның эчтәлеге безнең бәйрәмгә караганда күпкә баерак. Сабан туе соңгы вакытта җыр һәм спорт бәйрәменә әверелеп бара. Татарлык, борынгыдан килгән гореф-гадәтләр югала. Ә аларның бәйрәменә милли тел, гореф-гадәт, борынгыдан сакланып килгән тәртип салынган. Якут бәйрәмен күргәч, Сабан туен оештыруга бөтенләй башкача караш туды», – диде Президент, узсын өчен генә бәйрәм оештырган кайбер түрәләрнең колакларын торгызып.

Ул да башкалада татар телен куллануда күзәтелгән үзгәрешләрне яхшы яктан бәяләде. Башка районнарда да уңай эш алып барылуын, район җитәкчеләренең милли мәсьәләләр буенча атна саен хисап тотуын белдерде. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенең бик әйбәт эшли башлавын билгеләп үтте һәм моның өчен Марат Әхмәтовка рәхмәт әйтте. «Безнең резервлар бик зур. Монда акча дип тора торган түгел. Без эшләмәсәк, моны башка кеше эшләми, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Без бит игътибарны татар теленә генә бирмибез. Удмурт, мари, чуаш һәм башка телләрне дә укытуны таләп итәбез, чөнки һәр милләтнең үз телен өйрәнәсе килә».

Президент туган телне өйрәнүдә гаиләнең роленә басым ясап, гаиләдә телнең кулланышын үстерү буенча яңа проектлар тәкъдим итүне сорады.

– Гаиләдә татарча сөйләшү булмаса, мәктәптә генә туган телне сеңдерү бик авыр. Саф татар мәктәбе булса ярый, атнасына ике-өч сәгать укыту гына гаиләдән башка зур нәтиҗә бирми. Телгә ихтыяҗ булмаса, аңа өйрәтү бик авыр. Бу юнәлешләрдә эшләрбез. Без булдырабыз. Ләкин булдырмаган җирләр дә бар, тырышырбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

«Без – Ульян татарлары»

Ульян өлкәсе татарлары милли-мәдәни автономиясе башкарма комитеты рәисе Рәмис Сафин үз чыгышында берничә тапкыр әнә шулай әйтеп, андагы татарларның үҗәт һәм тырыш булуына басым ясады.

– Бездә 150 мең татар яши, мәктәпләрдә 12 меңләп татар баласы белем ала. Шуларның биш меңе туган телен мәктәпләрдә, дәрестән тыш түгәрәкләрдә өйрәнә. Ә калган 7 меңе татар телен өйрәнүдән мәхрүм. БДИга сылтау итеп, эти-әниләр, гариза язганда, туган теле дип рус телен күрсәтә. Баксаң, мәктәпләрдә гаризаларга алдан ук компьютерда ана теле графасына рус теле дип язалар икән. Миңа калса, бу – Россия законнарын тупас бозу. Мин бу хакта өлкәнең мәгариф бүлегенә җиткердем. Мәктәпләрдә дәреслекләргә, белешмәләргә беренди кытлык юк, – диде Рәмис Сафин. – Татар авылларында мәктәпләр ябылу безгә икеләтә кыенлыклар тудыра. Балаларны башка мәктәпләргә автобусларда йөртә башладылар. Анда исә тәрбия дә безнеке түгел. Татар телен укыту турында хыялланырга гына кала. Кайбер җитәкчеләр тарафыннан әйтелгән, татар телен гаиләдә, мәчетләрдә генә өйрәнергә кирәк, дигән сүзләр белән килешмибез.

Мәскәүдә ничек сөйләшәләр?

Башка төбәкләрдән килгән укытучылардан да мәктәпләрдә туган телгә булган мөнәсәбәт турында сораштык.

– Безнең Елга авылында 86 гына йорт бар. Мәктәптә 22 бала укый. 2018 елдан филиал булып кына калдык. Татар теле һәм әдәбияты атнага 1–2 сәгать укытыла. Татар теле саклана. Җырлыйбыз, биибез, үз ансамблебез бар. Әбиләр-бабайлар да татарча сөйләшә, дин тоталар. Тик урамда яшьләр русча аралаша, чөнки укучыларның яртысыннан күбе – тәрбиягә алынган балалар, – ди Красноярск краеннан килгән Гөлчирә Коленчук.

Эльза Нигъмәтҗанова Башкортстанның Дүртөйле районы Мәскәү авылында татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыта. Мәктәптә 206 бала укый.

– Авылыбыз зур. Татарлар күп яши, руслар бик аз. Татар теле һәм әдәбияты барлык сыйныфларда да атнага берәр сәгать укытыла. Укучылар бер-берсе белән мәктәптә русча сөйләшсәләр дә, дәрестә бары татарча гына җавап бирүләрен таләп итәм. Татар гаиләсендә үскәнгәме, туган тел саклана. Авылда яшьләргә эш урыны бар. Мәктәпкә ябылу куркынычы янамый, – ди Эльза Нигъмәтҗанова.

Үзебездән сорыйк

Туган телгә булган вазгыятькә, соңгы дүрт елдагы вакыйгаларга күз салыйк әле. 2018 елда 317 нче федераль законда туган телдә белем алу, Россия халыкларының туган телләрен өйрәнү хокукы белем бирү программаларының мәҗбүри өлешендә сакланды. Туган телләрне, шул исәптән туган тел буларак рус телен өйрәнү эти-әниләрнең гаризалары нигезендә башкарыла. 2019 елда Россия халыкларының туган телләрен укыту концепциясе һәм аны гамәлгә ашыру программасы кабул ителде. 2021 елда Россия Мәгърифәт министрлыгы яңартылган белем бирү стандартларын раслады. «Туган тел һәм әдәбият» предметы өлкәсенә Россия төбәкләренең дәүләт телен сайлап алу мөмкинлеге кертелде.

– Канун нигезендә белем бирү программасы мәктәп тарафыннан мөстәкыйль эшләнә. Туган телебезне укыту өчен барлык шартлар тудырылган: укытучыларыбыз, инфраструктура, дәреслекләр бар, методик ярдәм күрсәтелә. Туган тел укытылмаган бер генә мәктәп тә була алмый, – дип, хезмәттәшләренә мөрәҗәгать итте Илсур Һадиуллин. – Килеп туган вазгыять бездән мәктәп коллективлары һәм эти-әниләр белән хезмәттәшлекне тагын да активлаштыруны таләп итә. Нәтиҗәле эш алып барылса, әти-әни гариза да яза, теләктәш тә була, ярдәмен дә күрсәтә.

Республикабыз бакчаларында балалар ике дәүләт телендә тәрбияләнә. Соңгы өч елда гына да республикада 75 балалар бакчасы төзелгән.

– Бу бакчаларда туган телдә белем һәм тәрбия өчен шартлар тудырылдымы? Татар төркемнәре тупландымы? Тиешле кадрлар булдырылдымы? Үзебездән сорыйк. Балалар бакчаларында татар телендә белем һәм тәрбия бирүдә беренди каршылык юк. Бүген һәрбер бакчада милли тәрбия һәм белем бирүче төркемнәргә өстенлек бирү таләп ителә. Катнаш төркемнәр – күз буяу гына! Бигрәк тә бу район үзәкләренә һәм шәһәрләргә кагыла, – диде министр.

Сәрия МИФТАХОВА



Россиядә барлыгы 74 тел укытыла, 34 югары уку йортында 43 тел буенча укытучылар әзерләнә. Тик «туган тел» имтиханы нәтиҗәләре бер генә уку йортында да вузга керү сынавы буларак кабул ителми.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ӘТИЛӘР ӘНИ БУЛЫП ӘШЛИ

БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ ӘТИЛӘРГӘ ТИЕШЛЕ ПОСОБИЕЛӘР

Без дәүләт ярдәме, түләүләр әниләргә генә бирелергә тиеш дип уйларга күнеккән. Ләкин ул әтиләргә дә түләнә. Алар да балалар белән өйдә утыра, тәрбияли һәм дәүләттән, хатыннарыннан һәм хәтта балаларыннан да акча алырга мөмкин. Кайвакыт моның өчен аерым бер сәбәпләр була ала. Без шул шартларны барладык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Бала карау мәшәкатьлерәк»

Казанда яшәүче Айнур Сабитов кечкенә кызлары белән декрет ялында утыра. Хатыны Гүзәл студент кына икән әле. Шуңа күрә уйлашканнар да пособиене гаилә башлыгына рәсмиләштерергә булганнар.

– Беренчедән, Гүзәлнең рәсми төстә эш урыны булмагач, бала акчасы аз булыр, дидек. Икенчедән, укуын да туктатып торасы килмәде, моңа әниләре дә каршы иде, – ди Айнур. – Мин эштән тулысынча китмәдем, ярты ставкага гына күчтем. Бала йоклаган арада өйдән дә эшләү җае бар. Шуңа күрә хезмәт хакының яртысын да, бала караган өчен пособие дә алам.

Гаилә башлыгы әйтүенчә, җиде айлык кызларын иртәнге якта үзе караса, укудан соң әниләре кайтып җитә.

– Мин ишле гаиләдә үстем, – ди Айнур. – Гаиләдә өлкән бала булгач, эне-сеңелләремне тәрбияләү шактый эләкте. Шуңа күрә кызыбызны карарга бер дә курыкмадым. Хатыным, укугa киткәндә, сөтне савып калдыра. Хәзер инде балага акрынлап пюре, шулпалар да ашата башладык. Кызым белән саф һавада күп йөрибез. Гүзәл сессиясен япкач, көзгә кадәр тулысынча үзен балага багышлый алачак. Ә мин бу вакытта өстәмә эшләр алырга планлаштырам. Аннан соң инде Гүзәлнең укуының соңгы елы калып бара. Әйткәнемчә, мин бит көннәр буе өйдә утырмыйм. Гүзәл кайту белән эшкә китәм. Дөресен әйткәндә, эшем бала карау белән чагыштырганда җиңелрәк. Ләкин бер дә зарланмыйм. Кайбер әтиләр балаларын тәрбияләүдә бөтенләй катнашмый диярлек. Мин исә аның иң рәхәт, иң тәмле вакытларын күрә алуыма сөенәм.

Статистика мәгълүматлары буенча, Россиядәге әтиләрнең якынча 2 проценты декрет ялында утыра. Кызганыч, Татарстанда мондый саннар исәпкә алып барылмый. Республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәтендә аңлатуларынча, Татарстанда «әти» һәм «әни» дигән аерым статус юк. Ягъни балаларга кагылышлы ярдәмне «әти-әни» (родитель) ала, шунлыктан билгеле бер пособиене кем алганлыгын күзәтеп бару мөмкин түгел.

– Балалы гаиләләргә бирелә торган пособиеләр әтинекенә яки әнинекенә бүленми, – диде безгә матбугат хезмәт җитәкчесе Рафаэль Гыйниятуллин. – Әниләргә тиешле барлык төр пособиене әтиләр дә алырга мөмкин.

Дөрес, аның сүзләренчә, бер төр түләү бары тик әниләргә генә бирелә, ягъни әтиләр аңа дәгъва кыла алмый. Билгеле булганча, 2018 елдан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә, авылларда яшәүче әниләргә бер тапкыр акча бирә башладылар. Әгәр беренче баласын тапкан әни 25 яшькә җитмәгән булса, аңа – 50 мең сум, 29 яшькә кадәрге хатын өченче баласы тапкан икән, аңа 100 мең сум күләмендә акча түләнә.

СӨЕНЧЕ: МӨМКИНЛЕКЛӘР АРТА

Социаль ипотека программасында катнашучылар 1 июльдән торак бәясенең бер өлешен каплау өчен яңадан ана капиталыннан файдалана алачак. Бу хакта журналистларга Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының башкарма директоры урынбасары Булат Гыйльманов хәбәр итте.

Билгеле булганча, ике ел элек социаль ипотека белән фатир алучылар әлеге хокуктан мәхрүм ителгән иде. Бу аларга шактый гына мәшәкатьләр дә тудырды. Һәм, ниһаять, боз урыныннан кузгалды. «Кызганыч, карардагы үзгәрешләр без теләгәнчә үк килеп чыкмады. Хәзерге схема «Киләчәкне төзибез» кооперативы аша ана капиталы алуны күздә тота», – диде Булат Гыйльманов.

Ягъни торак фондының барлык фатирларын кооперативка яңадан рәсмиләштерергә туры киләчәк, шуннан соң кешеләргә Пенсия фондына барып, ана капиталы акчасын кулланырга рөхсәт бирүче документлар алырга кирәк. Әлеге вакытта фикер алышулар бара. Бу эшләр 20 июльгә тәмамланыр дип уйлыйлар. Халыктан гаризаларны шул вакыттан соң кабул итә башлаячаклар.

Билгеле булганча, ана капиталыннан социаль ипотека программасында катнашучы, балалары өч яшькә җиткән кешеләр файдалана ала. Моның өчен аларга Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак. Шулай итеп, Татарстанда 4 меңнән артыграк гаилә ана капиталыннан социаль ипотека торагы өчен түләү максатында файдалана алачак.

ШУЛАЙ ИТЕП, ӘНИЛӘР АЛЫРГА ТИЕШЛЕ ПОСОБИЕ КАЙСЫ ОЧРАКЛАРДА ӘТИЛӘРГӘ ТҮЛӘНӘ СОҢ?

Бала тугач, бер тапкыр бирелә торган түләү

Монда берничә шартның үтәлүе кирәк. Аның беренчесе: әгәр әни кеше хезмәт килешүе белән эшләмәсә, ә әтинең рәсми эш урыны булса, ярдәмне гаилә башлыгы ала. Яки әти-әниләрнең икесе эшләп тә, пособиене әти кеше алырга дип килешсәләр. Шулай ук ир белән хатынның берсе дә эшләмәгән очракта, ярдәмне, үзара килешү нигезендә, әти кеше алырга мөмкин. Ә инде әти-әни аерылышкан очракта, түләүне баланы тәрбияләгән кеше ала. Әлеге пособиегә гаризаны бала тугач, алты ай эчендә тапшырырга кирәк.

Күләме: быел 20472,77 сум.

Баланы 1,5 яшькә кадәр карау буенча айлык пособие

Бу очракта баланы әти карый яки гаилә башлыгы кыскартылган эш вакытына күчә. Шулай ук баланың әнисе рәсми төстә декретка чыгып, пособие алмаса, декрет ялын әтисе дә алырга мөмкин. Бу очракта да пособие аңа түләнәчәк. Бала карау буенча декрет ялын икегә дә бүләргә мөмкин. Аның бер өлешен – әни, икенчесен әти алса да була. Әгәр әти-әни рәсми төстә беркайда да эшләмәсә, социаль яклау бүлегендә пособиене аларның берсенә бирәләр.

Пособиенең минималь күләме: 7387 сум.

3 яшькә кадәрге баланы карау өчен ай саен

Әлеге төр ярдәмне 2018 елдан соң беренче яки икенче балалары туган (уллыкка алынган) гаиләләр ала. Бер гаилә әгъзасының кереме төбәкнең ике яшәү минимумыннан артып китәргә тиеш түгел. Баланың әнисе вафат булган, вафат булды дип игълан ителгән, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән очракта, пособиене әти кеше алырга мөмкин. Әгәр баланың әнисе исән-сау икән, социаль яклау бүлегенә яки Пенсия фондына үзе бара. Билгеле бер вакыт аралыгында әни кеше алып, соңыннан аны ата-ана хокукыннан мәхрүм итсәләр, гаризаны әти кеше тапшыра.

Пособиенең минималь күләме: 7667 сум.

3–7 яшьлек балаларга ай саен

Түләү гаилә әгъзаларының һәркайсына уртача керем күләме бер кешегә яшәү минимумы күләменнән артмаган очракта бирелә. Шулай ук аны билгеләгәндә милек тә исәпкә алына. Әлеге пособиене шулай ук ир дә, хатын да рәсмиләштерә ала. Тик бу очракта да әти кешенең бала белән бергә яшәве һәм әнинең пособиегә гариза язмавы кирәк.

Пособиенең максималь күләме – 11476 сум (төбәк яшәү минимумының 100 проценты булганда), 8607 сум (75 процент булганда), 5738 сум (50 процент булганда).

8–17 яшьлек балаларга ай саен

Әлеге түләүне әти кеше дә алырга мөмкин, тик төп шарт булып ир белән хатынның бергә яшәве тора.

Күләме: ул 10433 сумнан (республикада балалар өчен яшәү минимумы суммасы) чыгып исәпләнә. Мохтаҗ гаиләләргә аның яртысы – 5216 сум 50 тиен бирелә. Әмма аны исәпләгәндә, гаиләнең җан башына тигән уртача кереме яшәү минимумының яртысыннан ким икән, бу очракта акча 75 процент түләнә. Ягъни 7824 сум 75 тиен тәшкил итә. Әгәр гаиләнең җан башына уртача кереме яшәү минимумының 75 процентыннан ким икән, бу очракта 100 процент, ягъни 10433 сум түләнә.

Бала авырганда «больничный» алу

Авырган бала белән әти дә өйдә кала ала. Моның өчен аның рәсми төстә эш урыны булу да җитә. Шул ук вакытта әти белән әни «больничный»га чиратлап та чыга ала.

Ана капиталы

Халык телендә ана капиталы дип аталса да, законда ул «гаилә капиталы» буларак бара. Әгәр дә әни кеше мәрхүм булса яки ата-ана хокукыннан мәхрүм ителсә, Россия гражданины булмаса, аны әти кеше дә рәсмиләштерә ала. Шулай ук әлеге ярдәм баланы ялгызы гына уллыкка алучы ир-атка да бирелергә мөмкин. Сертификатны әни кеше алган очракта да, акчаны әти исеменә рәсмиләштерелгән ипотеканы капларга тотарга рөхсәт ителә.

Күләме: 2022 елда беренче балага бирелә торган ана капиталының күләме – 524,5 мең сум, гаилә беренче балага бу түләүне алмаган очракта икенчесенә – 693,1 мең сум. Ә беренче балага бу түләүне алган очракта 168,6 мең сум бирелә.

Ялгыз әтиләргә

8–16 яшькә кадәрге балаларны ялгызы тәрбияләүче әтиләр айлык пособие алырга тиеш. Мондый төр ярдәмне алыр өчен баланың туу турындагы таныклыгында бер генә әти-әни (аларның берсе вафат яки хәбәрсез югалган һәм башка сәбәпләр) күрсәтелүе яки ул әти кешенең алимент алуы кирәк. Тагын бер шарт – гаиләнең кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булу. Бу төр ярдәмне алыр өчен шулай ук милек булу-булмау да исәпкә алына.

УЕНЧЫК УЕН ТҮГЕЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Уйный белеп уйнасаң гына...

Киберспорт – Россиягә 2000 нче елларда гына килеп кергән күренеш. Тик без – электрон уеннарга корылган спорт төрен рәсми төстә спорт дип таныган беренче ил дә.

Гади итеп әйткәндә, киберспорт ул – команда яисә ялгызың гына компьютер уеннарында ярышу. Кызык өчен генә дип көн-төн компьютер уеннарында уйнау – бу әле киберспорт түгел. Спорт булгач, ул кешедән бик күп физик һәм акыл сәләтләрен таләп итә дигән сүз дә бит.

Россиядәге компьютер спорты федерациясенә нигез салучы, аның президенты Дмитрий Смит киберспортны хоккей йә футбол кебек спорт төрләреннән ким түгел дип саный. Үзе дә – күпсанлы турнирларда җиңүче булып танылган кеше. Компьютер уеннары белән балачагыннан дус. Балачак хыялын тормыш кәсебе иткән инде хәзер.

– Киберспорт – чын спорт инде ул һәм ул аның барлык таләпләренә, принципларына җавап бирә. Аның да үз әзерләнү, дисциплина системасы, төрләре, хөкемдарлык корпусы, турнир, чемпионатлары, бүләкләре, спорт разрядлары бар. Хәзерге вакытта халыкара киберспорт буенча федерация үз эченә 120 төрле федерацияне ала, – ди ул. – Киберспортта уңышка ирешкән кеше көндәлек тормышында да уңышка ирешә. Ул көнкүрештә кирәкле сыйфатларны үстерә: стресска каршы торучанлык, кыска вакыт эчендә мөһим мәсьәләләрне хәл итү, команда белән эшләү, җаваплылык хисе, аңгаррак...

Спорт таләпләренә җавап бирсә дә, киберспорт дигәч, күпчелекнең күз алдына нәрсә килеп баса соң? Компьютер алдында бөкрәеп, төн йокысын, ашын, ялын, укуын, эшен, шөгылен калдырып, күзе кызарганчы уен уйнап утырган кеше, билгеле. Күп очракта, яшүсмер, яшьләр. Шундый фикер калыплашкан инде: җансыз тимер тартмада юньле нәрсә аз, бу – вакытны бер файдасыз үткәрү, яшь организмның сәламәтлеген юк итү. Әмма Дмитрий Смит сүзләрен дә искә алып, моның алай түгеллеген дәлилләргә мөмкин.

Беренчедән, киберспортчылар (кибератлетлар дип тә әйтәләр) тәүлек әйләнәсе компьютерда гына утырмый. Иң элек бу – җитди һәм катгый режим саклау, остаз, психолог белән эш, стратегия һәм дисциплина да. Кибератлет өчен дөрес туклану да, йокы туйдыру да, физик күнегүләр дә бик әһәмиятле. Спорт бит инде ул шуңа да. Ә спорт – ярыш, иң көчлеләрне ачыклау дигән сүз. Шушыны гына белү дә киберспорт дөньясына башка күзлектән карарга этәргеч бирә. Киберспорт кысасында компьютер уенын уйнау – шахмат турниры яисә футбол матчы кебек инде ул. Спортка охшаш тагын бер ягы – кибератлетларның да җанатарлары, гонорарлары була.

Компьютер гына димә!

Киберспортчылар турында социаль челтәрләрдә дә, телетапшыруларда да күп сөйлиләр. Хәтта Россия Президенты Владимир Путин теленнән дә алар турында еш ишетергә туры килә. Хөкүмәт дәрәҗәсендә киберспортны югары уку йортларына кертү турында да гел әйтәләр.

Киберспортчылар дөньякүләм танылган турнирларда җиңү яулый, шул рәвешле миллионнар ота, яшь кенә булсалар да, «Forbes» исемлегенә керәләр. Араларында Татарстан егет-кызлары булуы да сөендерә. Кайберләренең тормыш тарихларына кызыгып, аларга башкалар да иярә. Дөресен әйткәндә, күп кенә яшьләр хәзер киберспортчыларны танылган Роналдо һәм Мессига караганда да күбрәк ярата. Һәр заманның үз каһарманы шул. Алар турында көн дә ишетмәсәк тә, уңышларын танымау дөрес булмас.

Мисал өчен, Денис electronic Шәрипов – 2017 елдан бирле киберспортның шактый «борынгы» саналган дисциплинасында чыгыш ясый. Аңа – нибары 23 яшь. 17 турнир җиңүчесе. Якынча 1,4 млн доллар акча эшләгән. Уенчы буларак шәхси күрсәткечләрен дә мактый...

Айрат Silent Газиев. Хәзер инде остаз. Заманында киберспорт буенча популяр турнирларда катнашып, тәҗрибә туплаган егет. Киберкарьерасы кысасында 324 мең доллар акча эшләп өлгергән.

Аяз nAts Әхмәтшин. Дөньядагы иң яхшы киберуенчыларның берсе дигән даны бар егетнең. Дөньякүләм чемпионатларда җиңү яулый. Аяз – «Forbes»ның 30 яшькә кадәрге иң уңышлы 30 Россия кешесе исемлегендә.

vk.com/mck_kitts

Сан

➤Россиядәге киберспорт аудиториясе – 12 миллионнан артык тамашачы.

➤Казан халкының 54 проценты мәктәпләрдә уеннар уйлап табу, киберспорт кебек дисциплиналар кертү яклы. «ResearchMe» тикшеренү үзәге белгечләре оештырган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә. 11 проценты аларны мәҗбүри итәргә кирәк дигән фикердә.

➤72 процент казанлы балаларына компьютер уеннарын уйнарга рөхсәт итә. һәр дүртенчесе бу шөгыльгә уңай карый икән. 19 проценты балаларның бу өлкәдә карьера ясауларына да каршы килми.

➤Былтыр «The International-2021» чемпионатында җиңү яулаган Team Spirit командасының (командасоставында Татарстаннан да егетләр бар) приз фонды 18,2 млн долларны тәшкил итте.

Екатерина aka Мисс Киттин. Екатеринага, киберспорт юнәлешендә беренче адымнар ясаган вакытта, каршылыклы фикерләрне күп ишетергә туры килә. Янәсе, бу – кызлар уены түгел. Егетләр исә: «Ничек кызларга җиңелеп була инде?» – дип мыскыллаган. Екатерина өстәрәк телгә алган егетләр кебек миллионнар эшләмәсә дә, киберспортта кызларга да урын барлыгын һәм моның вакытны бушка уздыру гына түгел икәнен дәлилләүче мисал булып тора.

Җылы сүз генә җитми

Алдарак киберспортчыларның тренер һәм психологлар белән эшләвен язган идек. Анастасия – киберспортчылар психологы. Шактый абруйлы саналган командалар белән эш итә. Тумышы белән Иркутскидан.

– Киберспортта да, гадәти спорттагы кебек үк, психолог эшчәнлеге кирәк. Иң төп вазыйфабыз – тренерны һәм уенчыларны нәтиҗәгә китерә торган ысулларга һәм техникаларга өйрәтү. Бу нәтиҗәнең сыйфатына да йогынты ясарга тиеш, – ди Настя. – Психолог уенчыларның көчле сыйфатларын үстерергә, кайсыларын киресенчә йөгәнләргә өйрәтә. Киберспортчыларның психологы барлык уеннарны карап барырга, уенчылар белән бик күп аралашырга тиеш. Хәтта тренировкаларына да йөрергә, аларны күзәтергә, тыңларга. Һәр вак-төяк саналган нәрсә дә мөһим бирелә. Үл төрле проблемаларның вакытында күрергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, стресс, кызыксыну кимү, хафалану. Кыскасы, нәтиҗә өчен эшлисең икән, бу эшкә үзеңне тулысынча багышларга кирәк. Бу – зур эш.

Кирәге бармы?

Дәүләт Думасының Физик культура һәм спорт комитеты рәисе урынбасары Әмир Хәмитов әйтүенчә, киберспорт үсеше буенча Россия алдынгылар унлыгына керә. «Тармакның спорт буларак кына түгел, икътисади мөмкинлекләрен дә исәпкә алырга кирәк. Хәзерге вазгыятьтә бигрәк тә», – дигән фикердә ул.

2022 елның апрелендә Дәүләт Думасында илнең киберспорт тармагының киләчәге, спортчыларны Россиядә калдыру ысуллары турында фикер алышканнар иде. Уен уйнап җыйган сәләт-тәҗрибәне икътисадның төрле тармакларында да кулланып була бит дигән хыяллары булды сәясәтчеләрнең.

Тәкъдимнәр күп яңгырады. Әйтик, араларында киберспортчыларга армиядә хезмәт итүне кичектереп тору яисә махсус киберроталар булдыру, югары уку йортларына төп конкурстан тыш кабул итү, фатир алганда ташламалар бирү кебек кызыксындыру чаралары бар иде.

Ярышлар оештыручылар турында да онытмадылар. Аларга да стимул кирәк бит. Дәүләт андыйларга ташламалы кредит бирү, салым ставкасын кимету, импорт алмаштыру җәһәтеннән кирәкле программа тәэминаты, уен платформаларын үзебездә җитештерү кебек адымга әзер. Әмма бу хыялланудан ары узармы – сорау ачык кала.

Соңгы елларда Татарстан да киберспорт юнәлешендә алга китте. Дөньякүләм турнирларда үзебезнекеләр җиңүен күрә торып, бу тармакны үстермәү ялгыш булыр иде, әлбәттә. Әйтик, быел Казанда БДБ илләреннән килгән яшьләр катнашында киберспорт буенча Татарстан Президенты кубогына ярыш узачак. 2019 елда Казан шулай ук бу спорт төре буенча Россия Кубогы финалын кабул иткән иде. Башкаланың берничә халыкара турнирны үткәрү мөмкинлеге дә булган иде хәтта. Әмма мәгълүм сәбәпләр аркасында, бу хокуктан мәхрүм ителде.

Моңа карамастан, 2024 елда Казан әлегә кадәр күрелмәгән халыкара спорт ярышын – «Киләчәк уеннары-2024»не оештырачак. Татарстан башкаласын сайлаулары да гаҗәп булмаска тиеш: республика көчле IT-инфраструктура белән мактана ала, «Иннополис» махсус икътисади зонасында 323 инновацион компания эшли, яңа IT-квартал ачылырга тора. Моңа Казанның кунакчыл һәм яңа ярышларга һәрвакыт ачык булуын да өстәсәң...

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч сүзе

Галия ГЫЙМАДИЕВА, психолог:

– Россиядә киберспортны рәсми төстә спорт төре буларак таныйлар. Ата-аналарга да моны аңларга кирәк. Теләсә кайсы спорт күнекмәләр һәм режим таләп итә. Ата-анага исә әнә шул хакта сөйләшергә һәм килешә белергә кирәк. Баланың физик сәламәтлеге, укуы да мөһим бит әле. Киберспорт, хобби булсынмы, профессиональ мавыгумы, укуга да, тормышка да комачау итәргә тиеш түгел! Кыскасы, алтын урталык кирәк. «Минем фикер генә бар» дип булмый, килешү ул – ике якның да фикере һәм ике якны да канәгатьләндерерлек нәтиҗәгә килү.

Бала чама хисен югалтмасын, виртуаль дөньяга тулысынча күчмәсен өчен, чынбарлыкта да альтернатива табу кирәк. Кемгәдер үзен каһарман итеп тою, кемгәдер команда белән уйнау ошый. Бала белән шулар турында сөйләшергә кирәк һәм, әйткәнемчә, чынбарлыкта да шуның альтернативасын табарга. Чынбарлыкта үзен бәхетсез тойган бала виртуаль дөньяга баш-аягы белән чумачак.

Раил ШӘМСЕТДИНОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе, педагогика фәннәре кандидаты:

– Хәзерге көндә психологлар да, балаларның компьютер каршында утыру вакытын контрольгә алырга кирәк, ди. Максатсыз утырмасыннар өчен, сәгатьләрне тәртипкә салырга. Ә моны системалы, хөкүмәт дәрәҗәсендә башкарырга кирәк. Нинди очракта тәртипкә сала алабыз? Әгәр дә ярышлар, кызыксындыру чаралары уйлап тапсак. Киберспорт юнәлешен хуплыйм. Балалар анда күп нәрсәләргә өйрәнә. «Киләчәк уеннары»ның Татарстан башкаласында узуы да күп нәрсәне сөйли. Файдасы булачак, балаларны әзерли, өйрәтә башлаячаклар, бу әкренләп укыту системасына да киләчәк. Киберспорт балада мантыйкый фикерләү, команда белән эшләү кебек сыйфатларны үстерә. Командада, бергәләп эшли белү – бик мөһим ул. Безнең Татарстанда барысы да бергәләп, бердәм булып башкарыла бит.

Хәзер интернетта максатсыз утыруның аяныч нәтиҗәләре турында күп ишетеп торабыз. Менә шулардан саклап калырга булыша торган спорт төре дә әле бу.

4 июль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20, 01.10 «Семь дней +». Руслан Айсин 12+
00.45 «Каравай» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Наил Әюпов турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Максим Матвеев, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 Ольга Иванова, Никита Тезин, Юрий Батурин. «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.40 Мария Порошина, Вячеслав Разбегаев, Владимир Епифанцев. «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 14.55, 17.00, 19.25 Новости
06.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40, 03.00 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ФК «ПАРИ НН» (Нижний Новгород) – «Сочи». Трансляция из Москвы 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55, 17.05 «Закусочная на колёсах» 12+
18.20 «Громко». Прямой эфир
19.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ЦСКА – ФК «ПАРИ НН» (Нижний Новгород). Прямая трансляция из Москвы
22.15 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.35 «Есть тема!» 12+
00.55 «Парный удар» 12+
03.15 Новости 0+
03.20 «Макларен». Док. фильм 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова» (S) 12+
09.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.40 Премьера. Сергей Шаталов, Татьяна Рассказова «ДАЙВЕР» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
01.55 «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». Шёпот 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ЯСНОВИДЯЩАЯ». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ВЕДЬМА». 1-я – 4-я серии 16+
22.30 «Порча» 16+
23.00 «Знахарка» 16+
23.35 «Верну любимого» 16+
00.10 «Понять. Простить» 16+
01.05 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 9-я и 10-я серии 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 00.15 «ДАЧНАЯ ПОЕЗДКА СЕРЖАНТА ЦЫБУЛИ» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Оружие Победы» 12+
13.40, 14.05 «ОТРАЖЕНИЕ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Загадки века». Док. сериал. «Операция «Бернхард». Фальшивомонетчики Третьего рейха» 12+
22.35 «ПРОЕКТ «АЛЬФА» 12+
01.30 «ЖАЖДА» 12+
02.50 «ДЖОКЕРЪ» 16+
04.40 «Москва фронту». Док. сериал 16+
05.00 «ОТРАЖЕНИЕ» 16+

5 июль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «МОЁ КОЛЕСО ФОРТУНЫ. НИКОЛАЙ ЗЕЛЕНОВ» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Телефильмы. «Менделеев и элементарные частицы» и «Вишневский. «Да здравствует жизнь!» 12+
00.40 «Каравай». Мастер народных промыслов 6+
01.05 «Уроки истории». Тюрко-татарские государства 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Кыр казлары артыннан». Мәсгуть Имашев турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 К юбилею Карена Шахназарова. Елизавета Боярская, Максим Матвеев, Виталий Кищенко, Кирилл Гребенщиков. «АННА КАРЕНИНА» 12+
00.55 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ» 12+
02.40 «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 14.55, 17.00, 19.10 Новости
06.05, 18.20, 22.50 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 Специальный репортаж 12+
09.30 Футбол. Кубок PARI Премьер. ЦСКА – ФК «ПАРИ НН» (Нижний Новгород). Трансляция из Москвы 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 «Кубок PARI Премьер». Спец. репортаж 12+
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55, 17.05 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
19.15 Тяжёлая атлетика. Чемпионат России. Трансляция из Хабаровска 0+
20.30 Футбол. Лига чемпионов. Финал. «Милан» (Италия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
23.40 «Есть тема!» 12+
00.00 Смешанные единоборства. UFC. Хабиб Нурмагомедов против Камала Шалоруса. Трансляция из США 16+
00.45 Смешанные единоборства. UFC. Конор МакГрегор против Дастина Порье. Трансляция из США 16+
01.10 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/8 финала. «Атлетико Минейро» (Бразилия) – «Эмелек» (Эквадор). Прямая трансляция
03.15 Новости 0+
03.20 Лёгкая атлетика. Первенство России среди юниоров. Трансляция из Чебоксар 0+
05.05 «Дети Гермеса и Афродиты» 12+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова» (S) 12+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.55 «ДНК» (S) 16+
19.50 Остросюжетный сериал «СТЕПНЫЕ ВОЛКИ» (S) 16+
21.40 Премьера. Детективный сериал «ДАЙВЕР» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
01.55 Детективный сериал «ДИКИЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». Батарейка 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ЯСНОВИДЯЩАЯ» 16+
19.00 «ВЕДЬМА». 5-я – 8-я серии 16+
22.25 «Порча» 16+
23.00 «Знахарка» 16+
23.30 «Верну любимого» 16+
00.05 «Понять. Простить» 16+
01.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.55 «ОТРАЖЕНИЕ»16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15, 00.05 «ЕКАТЕРИНА ВОРОНИНА» 12+
11.20, 18.50 «Открытый эфир» 16+
13.25 «Оружие Победы» 12+
13.40, 14.05 «ОТРАЖЕНИЕ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
20.50 Новости дня 16+
21.50 «Улика из прошлого» 16+
22.35 «РИСК – БЛАГОРОДНОЕ ДЕЛО» 12+
01.35 «ТЫ ПОМНИШЬ?» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ

4–10 ИЮЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атнада шәп кенә уңышкаирешү өчен, беренчедән, үҗәт, икенчедән, кыю булырга кирәк. Бер дошманыгызны җан дуска әйләндерердәй кызык кына хәлләрнең килеп чыгуын көтегез. Хезмәттәшләрегез белән кызып-кызып бәхәсләшкәндә, үзегезгә кирәкле мәгълүмат ишетеп сөенерсез.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Кирәкле кешеләр белән элемтәләрегезне эштә файдаланудан тартынып тормагыз. Дәрәҗәгезне генә арттырачак бу. Атна ахырында якыннарыгызга кагылышлы яхшы хәбәрләр ишетерсез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Иҗат кешеләре өчен «йолдызлы сәгать» чоры! Илһамыгызны эшкә җигеп, саллы гына табыш алачаксыз һәм матди хәлегезне ныгытачаксыз. Мәхәббәттә романтик очрашулар чоры да әле бу...

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Якыннарыгыз белән мөнәсәбәтләрне тагын да җылытырдай хәлләр булып алыр. Җитәкчегез намуслы, тырыш булуыгызны күреп, бу сыйфатларыгызны тиешенчә бәяләү турында уйланыр. Моңарчы такыррак булган кесәгез әкренләп кенә калыная башлар.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Эшлекле элемтәләрне киңәйтеп, әйбәт кенә акча эшләү мөмкинлеге пәйда булыр. Бер танышыгыз, эч серләрен сөйләп, күңелегездә мең төрле сорау уятыр. Ял көннәре гаиләгездә әйбәт кенә сюрприз белән төгәлләнер.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Шикләнү-көнләшүләрдән, ниһаять, тулысынча котылу мөмкинлеге чыгар. Очрашулар, кызыклы кешеләр белән танышулар эчке дөньягызны яктыртып, күркәмләндереп җибәрер.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Эштә – киеренкелек. Аның каравы алыштыргысыз белгечкә әйләнәчәксез. Бу хәл дөньяга карашыгызны киңәйтеп, гаять зур планнар кора башлауга китерәчәк.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Уңышлы атна. Күңелегез теләгәннең барысы да диярлек тормышка ашачак. Өстәвенә әле атна ахырында тормышыгызга ниндидер бер яңарыш җиле дә үтеп керәчәк.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Нәрсәләргәдер ашык-пошык кына йомгак ясаудан сак булыгыз: ялгышып, бик тә уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Атна урталарында эштә бераз сүлпәнлек сизелер. Ял көннәрендә якыннарыгызга кагылышлы сөенечле яңалыклар ишетелер.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Киртәләр, кыенлыкларга карамастан, эшегез алга бара. Уңышыгызның кадерен күбрәк тою һәм аңлау өчен шулай кирәктер, мөгаен... Атна ахырында, бер тырмага икенче тапкыр шап итеп басканчы, ялгышыгызны аңлап алырга өлгерерсез.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Йомшаграк, сабыррак булырга тырышыгыз. Каты куллылык сезгә туры килми. Өстәмә керем чыганагы тәкъдим итәргә мөмкиннәр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Уңышлы атна. Гәрчә тормышыгыздан, тирәгездәге кешеләрдән бик үк канәгать булмасагыз да. Үз дигәнегездә нык торыгыз, әмма тупаслык күрсәтмәгез. Сезне ишетүләре мөһим.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2022 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр докторы, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең агач материаллар эшкәртү кафедрасы профессоры Просвирников Дмитрий Богдановичка – лигноцеллюлоза материалларын көчле су пары белән эшкәртү ысулын кулланып активлаштыруның гамәли аспектларын эшләү һәм файдалануга тапшыруга зур өлеш кертүе өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, «В.Б. Шнепп исемендәге Үзәктән кудыру һәм ротор компрессорлары фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык институты» акционерлык җәмгыяте газ кудыру агрегатлары бүлекчәсенең җылылык алмашу аппаратурасы бюросы баш белгече Хәбибуллин Илмир Илдар улына – Россия Федерациясе газ тармагы модульле компрессор станцияләрендә санлы һәм физик модельләү ысулларын кулланып интенсивлаштырылган җылылык алмашулы модульле конструкциянең маен һава агымы ярдәмендә суыту буенча энергия сакчыл сарыф итәлә торган аппаратлар эшләүгә зур өлеш кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең реактив двигательләр һәм энергетика җиһазлары кафедрасы өлкән укытучысы Хәлиуллин Руслан Рафаэль улына – югары дәрәҗәдә нәтиҗәле энергетика җайланмалары һәм газ турбиналары двигательләре эшләү һәм җитештерүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 27 июнь
№ ПУ-439

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

МИҢ ГЕНӘ ДИМӘ

Тире яман шеше – меланома – иң мәкерле чирләрнең берсе санала. Еш кына чирнең иң азган мәлендә ачыклана ул. Шуңа күрә белгечләр тәндәге һәр яңа миң, тап, үзгәрешкә игътибарлы булырга киңәш итә. Кояш нурларын мулдан сипкән җәй көнендә бигрәк тә сак булырга кирәк.

Республика клиник тире-венерологик диспансеры табиб-дерматовенерологы Вероника БУХАЛОВА меланомага кагылышлы сорауларга җавап бирде.

:: Вероника Андреевна, яшерен-батырын түгел, «меланома» диагнозын ишетүгә, кеше төшенкелеккә бирелә, аны үлем карары итеп кабул итә...

– Юк, аны үлем карары итеп кабул итү һич кенә дә дөрес түгел. Башлангыч чорда ачыкланса, чирне аздырмыйча калып була. Меланома бик озак еллар дәвамында, организмга метастаза җибәрмичә, тән тиресенең эчке катламында гына «яшәргә» мөмкин.

:: Ул нидән гыйбарәт?

– Меланома – пигмент күзәнәкләреннән үсә торган яман шеш. Икенче төрле әйтсәк, ул меланин матдәсе эшләп чыгара торган күзәнәкләр – меланоцитларның азып китүе аркасында пәйда була. Еш кына ул тәндәге коңгырт төстәге яссы тапны хәтерләтә. Әмма меланома төрле төстә булырга, әйтик, шул ук коңгырт, кызгылт һәм зәңгәрсу төсләр катнашмасыннан да торырга мөмкин. Төен формасындагы меланома бик тиз үсә, ул канарга да мөмкин.

:: Кемнәргә аеруча сак булырга кирәк?

– Ультрашәмәхә нурлар меланома килеп чыгу ихтималын арттыра. Шуңа күрә кояшта чамадан тыш кызынучыларга, солярий белән мавыгучыларга аеруча сак булырга киңәш ителә. Нәселендә тире яман шеше белән авыручылар булган кешегә дә үз сәламәтлегенә, бигрәк тә тән тиресенең торышына игътибарлы булу кирәк. Тәндә күпсанлы яки гадәти булмаган миңнәре булган кешеләр дә – хәвеф төркемендә. Ак тәнле, сары чәчле кешеләр меланомага тиз бирешә. Балачакта тән тиресе кабарып чыкканчы кояш астында «янулар» да, үсә төшкәч, тире яман шешенә әверелергә мөмкин.

:: Бу чир балалар арасында да күзәтеләме?

– Күзәтелә, әмма бу – бик сирәк күренеш. Әгәр баланың тәнендә гадәти булмаган миң пәйда булса, аны тиз арада табибка күрсәтү хәерле.

:: Меланома тәннең кайсы урыннарын «ярата»?

– Тәннең теләсә кайсы өлешендә пәйда булырга мөмкин. Шуңа күрә аның бармы-юкмы икәнлеген тикшерү өчен, тәннең табан, тырнак астыннан башлап чәч

төпләренә кадәр – һәр өлешен яхшылап карарга кирәк.

:: Кайсы очракта кичекмәстән табибка күренергә?

– Тәнегездәге миңнәр саны 50дән артса, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Миң төсен үзгәртсә, үсә башласа да, чаң сугарга җирлек бар. 35 яшьтән соң тәнегездә яңа тап яки миң пәйда булса, нәселегездә тире яман шеше белән авыручылар булса, кояшта кызыну белән мавыксагыз да табибка күренү хәерле.

:: Миңнәрне алдырырга, яндырырга ярыймы?

– Миң алдыруның бернинди зыяны да юк. Диагнозны төгәл ачыклау өчен, аның бер өлеше яки миң тулысынча алынырга мөмкин. Ул расланган очракта, әлеге миң чирнең ни дәрәҗәдә азганлыгын ачыклау өчен дә кирәк. Әгәр меланома бик нечкә һәм башлангыч чорда ук ачыкланган икән, миңне алып ташлау меланоманы дәвалауның бердәнбер юлы булып тора.

:: Меланоманы кисәтү өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга?

– Тән тиресен балачактан ук кояш нурларыннан сакларга кирәк. Хәзер телефоннарда һава торышын күрсәтүче махсус кушымталар бар. Аларда УФ-индекс (ультрашәмәхә нурлар ешлыгы) та күрсәтелә. Әгәр ул 2дән зуррак булса, урамга чыкканда тәнгә кояштан саклаучы махсус чаралар, кремнар сөртергә кирәк. Моннан тыш тән тиресен дөрес сайланган кием, баш киеме ярдәмендә сакларга кирәклеген дә онытмагыз. Кояшта иртән сәгать унга кадәр яки кичке сәгать дүрттән соң – кояш бераз сүрелгәч кызынсагыз яхшырак.

Кисәк булуы куркыныч

Әле бу көннәрдә генә йөрәк өянәгеннән кинәт вафат булган 48 яшьлек танылган җырчы Юрий Шатуновның үлеме күпләрне шок хәлендә калдырды.

Ни кызганыч, бүген яшьләр арасында кисәк үлем-китем очраклары аеруча еш күзәтелә. Көнбатыш табиблары хәтта бу күренешкә рәсми атама да бирергә мәҗбүр булган. Фәнни телдә ул хәзер «кинәт үлем синдромы» дип йөртелә. Австралиянең гомуми практика табиблары көллиятеннән алынган мәгълүматларга караганда, кинәт үлем синдромы, гадәттә, 40 яше тулмаган кешеләр арасында аеруча еш очрый. Ниндидер хроник авырулары булган кешеләргә генә түгел, сау-сәламәт кешеләргә дә яный бу куркыныч.

Белгечләр узган ел кисәк үлемнән вафат булган 4 мең кешенең тарихын тикшергәннән соң аларның күбесендә үләр алдыннан аң югалту, ярсыганда, физик күнегүләр ясаганда, хәрәкәтләнгәндә күзән җыеру кебек билгеләр күзәтелгәнен ачыклаган. Кайберләренең туганнары арасында да кисәк кенә үлеп китүчеләр дә булган.

«Шуңа күрә без кисәк үлем очраклары нәселдән дә күчә аладыр дип фаразлыйбыз. Нәселдә шундый очраклар күзәтелгән икән, кичекмәстән табибка, аерым алганда кардиологка, күренергә киңәш итәм», – ди Австралиянең Бейкер йөрәк һәм шикәр чире институты докторы Элизабет Паратц.

Белгеч күкрәк читлеге авырту, тын кысылу кебек билгеләр күзәтелгәндә дә кичекмәстән табибка күренергә киңәш итә. «Кешеләр еш кына йөрәк өянәге белән йөрәк туктауны бутый. Йөрәк өянәге кан тамырлары тыгылудан барлыкка килә. Йөрәк туктаганда исә әлеге мөһим орган кисәк кенә эшләүдән туктый да шуның белән шул. Кеше йөрәк өянәгеннән үлгән булса, ярганда анда тромб өзелгәнлеге күренә, кисәк үлемнән вафат булганда, йөрәк ничек бар, шул килеш калган, нибары туктаган гына була», – ди Элизабет Паратц.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа Зеландиядә солярийга килгән 30 яшьлек кыз кисәк кенә вафат булгач, Австралиядә кисәк үлем очракларының исәбен алып бара башлаганнар. Белгечләр, Австралиянең Виктория штатында ел саен кисәк кенә йөрәк туктаудан 50 яшькә кадәрге 750ләп кеше үлүен ачыклаган. Алар арасында 100 кешенең йөрәге ни сәбәпле туктаганны әле дә булса ачыклый алмаганнар. Ул хәтта мәетне яргач та күренмәгән. «Шуңа күрә бу синдром кисәк үлем дип атала да инде. Без аның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен күз алдына да китерә алмыйбыз әле», – дип кисәтә белгечләр.

«Комсомольская правда» газетасыннан

Сабагын да әрәм итмә!

Төче чия (черешня) шикәр, органик кислоталарга, витаминнарга һәм минералларга бай. Ул кан басымын төшерергә ярдәм итә, кан тамырларын ныгыта, кан составын яхшырта. Моннан тыш ул организмны токсиннардан чистарта, холестеринны көйли. Төче чия баллы булганга күрә, ул организмга туклык хисе бирәчәк. Өстәвенә анда калория бик аз: фигура бозылыр дип курыкмыйча, бу чияне күпме теләсәң, шулкадәр ашарга мөмкин. 100 грамм төче чиядә 50 ккал, 1,1 грамм аксым, 0,4 грамм май һәм 11,5 грамм углевод бар. Төче чияне аллергиядән, шикәр диабетыннан интегүчеләргә ашарга ярамый. Бигрәк тә кечкенә балаларда аллергия башланырга мөмкин.

Төче чиянең җимеше бер файдалы булса, аның сабагы икеләтә шифалы. Төнәтмәләре ярдәмендә бик күп кенә авырулардан котылырга мөмкин, дип ышанган борынгылар.

✱**Бөердә таш булганда.** Ун данә төче чия сабагына 1 стакан су салып, 10–15 минут кайнатырга. Бу төнәтмәне көн дәвамында өчкә бүлеп, ашар алдыннан эчәргә киңәш ителә.

✱**Буыннар сызлаганда.** Бу очракта да шундый ук төнәтмә әзерләнә. Әмма монда инде ул 30–40 төче чия сабагына 1 литр су салып ясала. Бер тәүлеккә шушы төнәтмәнең яртысын эчәргә кирәк.

Ике уйдырма

Табиб-терапевт Гөлназ ГАЛӘВЕТДИНОВА ачыклык кертте.

✓**Туңдырма ашасаң, тамакка бәрә.** Тамак авырулары күбесенчә төрле вирус һәм бактерияләр аркасында килеп чыга. Аны башка кешедән йоктырырга да мөмкин. Туңдырманың моңа бер катнашы да юк.

✓**Бармак шартлатып уйнау артритка китерә.** Кешенең буын куышлыгы синовиаль сыекча белән тулган. Анда газ куыклары җыелырга мөмкин. Алар шартлаганда, без бармак шартлаткандагы сыман тавыш ишетәбез. 20 минуттан бу куыклар кабат пәйда була. Тагын шул ук күренеш кабатланачак. Кыскасы, бармак шартлатуның артритка бернинди дә катнашы юк.

Валентина
СЕМЕНОВА

БАКЧАНЫҢ КЫЗГАН МӘЛЕ

Сорауларга «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВА җавап бирә.

Яңгырлы, суык җәй үзенекен итә – ачык грунттагы помидорлар начар үсә. Үсентеләргә хәл кертү, аларны фитофтороздан саклау өчен нәрсә эшләргә мөмкин?

Галина ВАСИЛЬЕВА. Чистай районы

– Чәчәк ата башлаган чорда чирне кисәтү өчен биологик препаратлар: «Псевдобактерин-2», «Фитоспорин-М» яки бордос сыекчасы сибү томатларга бәләзәм сипкәндәй тәэсир итеп, аларны чирдән саклый. Ике көнлек көл төнәтмәсе сибү дә томатларны сәламәтләндереп җибәрә. Моның өчен 10 литр суга 250–300 грамм көл салып, эремә әзерлибез. Тонганнан соң, сөзеп, үсентеләргә бөркибез. Чүпрә эремәсе исә фитофтороздан коткаруга ярдәм итеп кенә калмыйча, үсентеләрне бик әйбәт ашлый да. 10 литр җылы суга 100 грамм кисәкле чүпрә салып, бик әйбәтләп эретәбез һәм шуны помидор куакларына сибәбез.

Июль аенда һәрбер культураны тукландырырга кирәк. Органик ашлама сыйфатында тавык тизәге (1:25) яки сыер тизәге (1:10 нисбәтендә) эремәсе, көл төнәтмәсе (10 литр суга 1 стакан исәбеннән), чапкан үлән төнәтмәсе кулланырга мөмкин.

Помидор үсентеләренең үги ботакларын даими кисеп торыгыз. Шул ук вакытта җиргә тигән яфракларын кисеп ташлагыз. Ник дигәндә, яфракка туфрактан фитофтороз күчәргә мөмкин.

Сарымсак тәме килеп торган сусыл кыяклы «слизун» суганын утыртып карыйсым килә. Белүемчә, аны җәен утырталар. Төгәлрәк – кайсы айда?

Сәвия ГАЛИМУЛЛИНА. Балык Бистәсе

– Кыяклары «витаминнар келәте» – күпьеллык «слизун», «батун», «шнитт» суганнарын җәй урталарында чәчәләр. Кузгалак һәм рәвәк (ревень) утырту чоры да бу. Башка яшел тәмләткечләргә килсәк, укропны җәй буе һәр 15–20 көн саен (шушы вакыт эчендә өлгерә) чәчәргә мөмкин. Ә кресс-салат ике атна узуга ук өлгерә. Руккола исә 5–6 көннән тишелеп чыга. Җәй уртасында утыртылган петрушка һәм «порей» суганы бакча сезоны ахырында өлгерә. Сүз уңаеннан, кузаклыларны – борчак, фасольне дә июльдә чәчәргә мөмкин.

vk.com

Кишер яфрагы бөтерелә. Нәрсә эшләргә икән?

Эльмира НӘБИУЛЛИНА. Саба районы

– Кишер бете белән зарарлангандыр, күрәсең. Яшел төстәге бу бетләр, канатлары булса да, очмыйлар, ә сикерәләр. Гадәттә алар бакча тирәсендәге ылыслы агачлардан күчә. Вакытында чарасын күрмәсәң, уңыш җыеп алганчы, кишер яфракларында үрчеп ятачаклар. Корткычтан котылу өчен түтәлне «Алатар», «Децис» кебек препаратлар белән эшкәртергә кирәк. Халык ысулын кулланып карарга – сарымсактан, ат кузгалагы, меңъяфрак, канлы үләннән төнәтмә ясап сибәргә була. Тәмәке тузанына көл кушып, түтәл өстенә сибү дә корткычлардан котылуга ярдәм итәчәк. Кер сабыны эремәсе дә (10 литр суга 300 грамм кер сабынын салып эретергә) кишер бетеннән әйбәт чара санала. Берничә тапкыр сипкәндә генә корткычны тулысынча җиңеп булачак.

Кәбестә яфракларынниндидер корткыч тишкәли башлады. Көл суы сиптем, әллә ни файдасын күрмәдем. Аннан котылу юлын әйтсәгез иде.

Нәҗия ИБРАҺИМОВА. Казан

– Җәй урталары җитеп килгәндә, кәбестәне гадәттә кәбестә чебене, үлән бете, ак күбәләк зарарлый башлый. Алардан котылу өчен үсентеләргә атнага бер тапкыр «Биостоп», «Фитоверм», «Лепидоцид» кебек препаратлар сиптерергә кирәк. Корткычлардан шулай ук көл һәм кер сабыны эремәсе, канлы үлән (чистотел) һәм әрем, кервән һәм тузганак эремәсе ярдәмендә дә көрәшергә мөмкин.

Белеп тор!

Юа-юа юылган...

Сабынсыз бер көн дә яшәп булмый. Чынлыкта каты сабын яхшыракмы, әллә сыегымы?

Казанның косметика кибете консультанты **Лилия ГАРИФУЛЛИНА** әлеге сорауга ачыклык кертте.

Өстенлекләре

Уңайлылык һәм гигиена күзлегеннән карaганда да, сыек сабын куллануның күпкә җайлы булуы бәхәссез. Кулга тотып сабынлыйсы булмагач, кисәклесендәге кебек, кемнәрдәндер калган бактерия-вируслар иярү куркынычы юк. Шул ук вакытта күпме сакласаң да, кипми һәм җебеми дә. Сыек сабыннан файдалану бик уңайлы һәм экономияле. Үзең белән сәяхәткә алу өчен дә уңайлы: җебеп-агып, киемне пычратудан куркасы юк.

Сыек сабынның составы шампунь һәм гельнекенә охшашрак ул. Аңа тән тиресен тәрбияләү өчен эфир майлары һәм башка матдәләр өстәлә. Кисәкле сабын тән тиресен саклагыч катламын юып төшереп, тиресне киптерсә, сыегы селтенең мондый тәэсиреннән котылуга ярдәм итә.

Составын һәм савытын кара

Сыек сабынны сайлаганда, составына игътибар итәргә кирәк. Фәнни телгә күчсәк, аны җитештерүдә калий тозлары, олеин, аурин кебек май кислоталары, тән тиресен йомшарткыч матдә – сурфактант кулланыла. Шулай ук сыек сабынга глицерин, бактериягә каршы матдәләр өстәлә. Кайвакыт сабын составында натрий тозлары булырга мөмкин. Мондый составлы сабынның сәламәтлек өчен дә, әйләнә-тирә мохит өчен дә зыяны юк.

Нормаль тире өчен глицеринлы, бактерияләргә каршы сабын, коры тире өчен – дымландыргыч, аллергиядән интегүчеләр өчен – гипоаллерген дигәнен сайлагыз, ди ул. Тагын бер мөһим әйбер – pH күрсәткече. ГОСТ буенча, шампуньдә һәм сыек сабында 10,0 санынннан артмаска тиеш.

Сыек сабынны хәзер пластик канистрлар, зур савытлар, герметик пакетларга тутырып саталар. Гадәттә ул арзанграк төшә. Зур савыттагы гигиена чарасы озакка җитә, әлбәттә. Ләкин составы начаррак: чөнки аңа консервантлар, «химия» күбрәк кушыла.

Бактерияләргә каршы

Коронавирус пандемиясе чорында бактериягә каршы сабыннарны кибет киштәләреннән кырып-себереп алдылар. Чыннан да, аның составындагы махсус матдәләр бактерия һәм вирусларны юкка чыгара, ди консультант кыз. Ләкин мондый сабын белән көненә бер тапкыр гына юынырга киңәш ителә. Чөнки составындагы агрессив матдәләре тән тиресен киптерә.

Аш-су

ҖИЛӘК ҺӘМ ЛИМОННАН ДЖЕМ

Алинә Хәйбуллова рецепты

Кирәк: *2 кило җиләк, 1,5 кило шикәр комы, 1 данә лимон.*

Виктория җиләкләрен юабыз һәм тишекле чүмечкә салып саркытабыз. Бөтен суы саркып бетәргә тиеш. Яфракларыннан чистартып, өлешләргә бүләбез. Җиләкләрне зур кәстрүлгә салабыз, шикәр комы өстибез. Согы чыксын өчен, 2 сәгать чамасы тотабыз. Лимон кабыгын – угыч аша чыгарып, йомшагын – ваклап турап, җиләк янына салабыз. Кәстрүлне салмак кына утка куябыз. Кайнап чыккач, күбеген җыеп алабыз һәм газны сүндерәбез. Суынганнан соң җиләк катнашмасын блендерга салып болгатабыз. Тагын бер тапкыр кайнатып чыгарабыз. Парландырылган банкаларга тутырып, капкач белән борып ябабыз.

АБРИКОСТАН БӘЛЕШ ӘЧЛЕГЕ

Вероника Денисова рецепты

Кирәк: *2 кило абрикос, 1 кило шикәр комы, 1 чәй кашыгы лимон кислотасы, 2 литр су.*

Абрикосны юып, икегә бүләбез һәм төшен алабыз. Өлешләрне кәгазь сөлгегә тезеп киптерәбез. Җимешләрне парландырылган чиста банкаларга тутырабыз.

Сироп әзерлибез: суга шикәр комы һәм лимон кислотасы өстәп, кайнатып чыгарабыз. Өрекле банкаларга кайнап торган сиропны агызып, шундук капкач белән борып ябабыз. Банкаларны, астын өскә әйләндереп, җылы әйбер белән каплыйбыз һәм бер тәүлектән соң салкынча урынга алып куябыз.

Белсәң, зыян итмәс

КЫРМЫСКА КӨЛДӘН КУРКА

Түтәлне җирән кырмыска басса, аннан котылу җиңел эш түгел. Мондый очракта оясына көл сибәргә кирәк. Болай эшләгәндә, бөҗәк бик тиз эзен суытачак.



КОРБАН АЛЛАҺКА ЯКЫНАЙТА

Корбан бәйрәме ел саен зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә билгеләп үтелә. Быел ул 9 июльгә туры килә. Мөселманнарның иң көтеп алган, изге бәйрәме бу. Корбан чалганда нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Корбанлык малына нинди таләпләр куела?

Корбан чалуга кагылышлы сорауларыбызга «Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН ачыклык кертте.

:: Корбан – ни дигән сүз? Аның диндәге хөкеме нинди?

– Корбан гарәп теленнән «якынаю» дип тәрҗемә ителә. Аллаһы Тәгалә безгә мал, бәрәкәт, ризык бирә. Адәм баласы шушы Аллаһы Тәгалә биргән ризыкны – үзенең акчасын, байлыгын чыгарып, аңа сарык сатып алып, Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, аның боерыгын үтим дип, корбан чала. Кеше бу гамәлне ихлас эшләргә тиеш. Аның бердәнбер нияте Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү, аңа буйсыну булырга тиеш. Корбанныниндидер башка максатлар белән чалырга ярамый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Шушы корбанның ите дә, каны да Аллаһка барып җитми. Әмма аңа сезнең тәкъвалыгыз барып җитә», – ди. Димәк, Аллаһы Тәгаләгә корбанның нинди ният белән чалынуы мөһим. Корбан чалу – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең сөннәте булып тора.

:: Нинди төр корбаннар була, аларның кайсы кайчан чалына?

– Аның иң беренче төре – Корбан гаетендә чалына торган корбан. Ул өч көн дәвамында чалына. Монда шунысын да белеп торырга кирәк: корбан бәйрәм намазыннан соң гына чалына. Юкса, иртүк торып, бәйрәм намазына кадәр үк корбан чалып куючылар да очрый. Болай эшләргә ярамый. Нәзер корбаны да бар. Ул Аллаһка ниндидер вәгъдә биргән очракта чалына. Мисал өчен, бик нык авырганда Аллаһы Тәгаләгә: «Ярабби Аллам, шушы чирдән коткарсаң, миң бер корбан чалыр идем», – дисең. Аллаһы Тәгалә сине авырлыктан коткаргач, шифасын биргәч, сүзеңдә торып, корбан чалырга тиеш буласың. Гакыйка корбаны бала тугач чалына. Малай туса, ике сарык чаласың, кыз туганда бер сарык чалына.

:: Корбан чалу кемнәргә тиеш? Аннан кемнәр азат ителә?

– Әйткәнемчә, корбан чалу пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең сөннәте булып тора. Мөмкинлеге булган һәркем корбан чалса, яхшы. Әмма ул мәҗбүри түгел. Корбан чалдырмау гөнаһ саналмый. Үзләре дә мохтаҗ кешеләргә исә корбан чалдыру мәҗбүри түгел.

:: Корбан чалуның нинди шартлары бар?

– Корбанга билгеле бер төрле хайваннар гына чалына ала. Мәсәлән, дөя, үгез, сыер, сарык һәм кәҗә. Дөя – биш яшьтән, сыер, үгез – ике яшьтән, кәҗә белән сарыкны бер яшьтән чалырга ярый. Әмма монда бер искәрмә бар. Әгәр сарык бер яшькә җитмәгән, әмма зур гәүдәле булса, аны да чалырга ярый. Чалынасы корбанны кыйбла ягына каратып салырга, иң мөһиме – куркытмаска кирәк. Хайванга яхшы мөнәсәбәт күрсәтергә – җирдән өстерәп бармаска, боргаламаска. Пычакларың алдан ук үткенләнгән булырга тиеш. Корбан малы каршында пычак күрсәтү, үткенләү дөрес түгел.

:: Корбанлык малына нинди таләпләр куела? Аны сатып алганда сатулашырга ярыймы?

– Корбанлык малы, иң беренче чиратта, бәрәкәтле, мул булырга тиеш. Кеше малның иң мулын сайлап чалырга тырышса, шул хәерле булачак. Корбанлык малының сәламәт булуы зарур. Ул аксаган, ябык, бер күзле, сынган мөгезле булырга тиеш түгел. Кыскасы, корбанга чалыначак мал кимчелексез булсын. Әйбер сатып алганда сатулашабыз, билгеле. Бу очракта да ул рөхсәт ителә. Әмма малны саткан кешенең дә күңелен төшермәскә кирәк. Уртак фикергә килеп, бәясен килешеп, мәсьәләне тыныч кына хәл итү әйбәт.

:: Бурычлы кешегә корбан чалырга ярыймы?

– Әйе, ярый, бурычлы кешегә дә корбан чалу рөхсәт ителгән. Әгәр аңа шушы бурычны кичектереп түләү мөмкинлеге бирелгән, ягъни аның бурычын кайтарып бетерергә вакыты бар икән, ул корбан чалдыра ала. Әгәр аннан бурычын бүген-иртәгә кайтаруын сорыйлар икән, ул иң элек бурычын түләргә тиеш.

:: Корбан итен ничек бүләргә, аның сөякләрен ничек урнаштырырга кирәклеген дә искә төшереп китегезче.

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм бер хәдисендә: «Корбан итенең өчтән бер өлешен үзеңә калдырасың, тагын өчтән бер өлеше белән туганнарыңны, якыннарыңны, күршеләреңне сыйлыйсың, калган өчтән бер өлешен мохтаҗларга таратасың», – дигән. Корбан малының сөякләрен дә ташларга ярамый. Аларны күмәргә кирәк.

:: Корбанны берничә кеше исеменнән чалырга ярыймы?

– Ярый. Әмма монда бер искәрмә бар: сарык белән кәҗә бары тик бер кеше исеменнән генә чалына. Әгәр кешеләр җыелышып, корбанны берничә кеше исеменнән чалырга теләсәләр, алар корбанга сыер, дөя яки үгез алырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең хәдисендә: «Сыер һәм дөя җиде кеше исеменнән чалынган», – диелә. Аның вакытында шундый хәл булган. Шуңа күрә берничә кеше исеменнән корбан чалдырырга җыенган кеше иң беренче чиратта әнә шушы хайваннарга игътибар итәргә тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Үлгән кеше исеменнән корбан чалу дөресме?

– Әгәр кеше исән вакытта: «Мин үлгәннән соң Корбан гаетендә минем исемнән корбан чалыгыз», – дип әйтеп калдырган булса, аның васыятен үтисең. Ләкин сарык алып, үлгән кеше исеменнән дип кенә корбан чалу бик үк дөрес булмас. Бу уңайдан пәйгамбәребезнең хәдисләре юк. Аңа дәлил һәм боерык килмәгән. Ул дөрес булып бетмәс. Шуңа күрә бу очракта үзең корбан чалган вакытта: «Шушы корбан миннән һәм бу дөньядан киткән фәлән кеше исеменнән», – дип әйтсәң, дөресрәк булыр.

:: Корбан чалганда мулла чакыру мәҗбүриме? Әллә доганы чалган кеше укырга тиешме?

– Юк, мулла чакыру мәҗбүри түгел. Киресенчә, кеше малны үзе дога кылып чалса, дөресрәк һәм хәерлерәк була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең сөннәте һәрбер кешегә корбанны үзенә чалырга кирәк дип өйрәтә. Кеше курыкса, үзе булдыра алмаса, башка кешегә дә мөрәҗәгать итә ала. Әмма ул мөрәҗәгать иткән кеше, һичшиксез, мөселман булырга тиеш. Корбан чалганда «Бисмиллә, аллаһуәкбәр, аллаһүмә тәкәббәл миннни» (Мәгънәсе: «Аллаһы Бөек, Аллаһым, шушы корбанны миннән кабул ит») дип дога кылырга кирәк. Моны һәркем эшли ала. Әгәр кеше корбан чалырга башка кеше чакырган булса, шул чалган кеше: «Бисмиллә, аллаһуәкбәр, аллаһүмә тәкәббәл минһү», – дип әйтергә тиеш. Бу очракта ул: «Я Раббым Аллам, бу корбанны кабул ит аннан», – дип тәрҗемә ителә.

:: Корбан чалдырмыйча, бер сарыклык акчаны хәер итеп мохтаҗларга бирсәң дә ярыймы? Ул корбан чалдыру белән бер үк дәрәҗәдә савап саналачакмы?

– Бу хакта шулай ук пәйгамбәребезнең хәдисләре юк. Әйткәнемчә, Корбан – якынаю дигән сүз. Корбан гаетендә менә шушы көнне кушылган гамәлләр кылынырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм шушы көнне иң яхшы сарык чалган. Без дә әнә шул үрнәккә таянырга тиеш. Үзебездән нәрсәдер уйлап чыгарып, корбан чалганчы, акчасын гына хәер итеп тапшырыйм әле дип эшне җиңеләйтү дөрес булмас. Динебез, Аллаһы Тәгалә кушкан кануннарны, боерыкларны үтәгән очракта гына сиңа савап булачак.

:: Корбанга чалынган малның тиресен ни эшләтергә?

– Корбанга чалынган малның тиресен сатарга ярамый. Ул диндә тыелган. Әмма бер искәрмә бар. Кайбер галимнәр, әгәр кеше тирене кергән акчаны сәдака итеп тарату нияте белән сата икән, бу гамәл рөхсәт ителә, ди. Әгәр бу тирене файдаланып булса, аны берәр кешегә бирергә яки үзең кулланырга мөмкин. Кулланып булмаса, корбан малының тиресен күмәргә кирәк.

Белеп торыгыз!

Корбанга чалынасы малның:
- ➤бер күзе дә сукыр булмаска;
- ➤аягы аксамаска;
- ➤колаклары тулысынча киселмәскә;
- ➤тешләре коелмаска;
- ➤койрыгының яртысыннан күбрәге киселмәгән булырга;
- ➤имчәкләре үз урынында булырга;
- ➤талчыккан, хәлсез булмаска;
- ➤тумыштан колаксыз яки койрыксыз булмаска;
- ➤чирләмәскә;
- ➤нәҗескә буялмаска тиеш.

СҮЗ УҢАЕННАН

Татарстанның Казыйлар шурасы һәм Голәмәләр шурасының бердәм карары белән нисаб күләме, барлык чыгымнардан һәм әҗәтләрдән тыш, 32000 сумны тәшкил итә. Корбан нисабының күләме 595 грамм көмеш бәясенә тиң. Шул рәвешле, мөселман кешесенең артык 32000 сум акчасы булганда, аның өчен корбан чалу фарыз санала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

…Авылда Сабан туенда керәшкә чыгарлык хатын-кызлар калмаган инде. Быел мәйданга чыгып бил алышучы булмаган. Китапханәче Гөлфирә Калиева әйтүенчә, сандыкчылар, иләк-чиләк, комган ясаучылар, балта осталары, итек басучылар, шәл сатучы, манучылары белән тирә-юньдә дан тоткан Күгәрчен авылы, ни кызганыч, картаеп бара.

– Шәл бәйләүчеләр дә олыгая инде. Яшьләр бәйләми. Алга китеш юк, арткарак барабыз. Яшьләр шәһәргә китә. Авылда яшьләр дип 45–50 яшьләрдәге буынны әйтергә була. Күбесе – пенсионерлар. Тик шуңа да карамастан, үз көнебезне күреп, матур гына яшәп ятабыз, – ди Гөлфирә Калиева.

Уңайлыклар җитми

Без элек гел саз ерып йөри идек, хәзер генә чирәм чыга башлады әле, дип сөенә авыл халкы. Тик барысы да түгел. Ике бала әнисе Ләйсән Мингарипова күрше Ямаш, Балтач, Күки авылларының асфальтлы юлларына кызыгып яши. Аның әйтүенчә, Күгәрчен урамнарына яхшы юл кирәк. Башка проблемаларга да тукталды ул.

– Әнә багана төпләрендәге чүпләрне күрәсезме? Чүпне сишәмбе җыялар. Кичен чыгарып куйсалар да була бит инде. Ә болай чүп атна буе багана төбендә ята. Тәртип җитми инде. Икенче мәртәбә килгәнче тора ул шунда. Чүп җыю өчен берничә урында савытлар урнаштырылса, шунда илтерләр иде, юк бит. Җәй көне су җитмәү дә үзәккә үтә. Безгә яңа фельдшерлык-акушерлык пункты да кирәк әле. Искесенә укол салдырырга гына төшәбез. Дарулар юк. Йөрәк авыртса да, балалар чирләсә дә, дәва таба алмыйсың, – ди Ләйсән Мингарипова, үпкәсен белдереп. – Берәр даруханә дә булсын иде. Ике бала тәрбиялим. Берсе группада, ул Лаешта шифаханәдә дәвалана әле.

Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы Альберт Сафиннан әлеге проблемаларга ачыклык кертүне сорадык. Башлык әйтүенчә, авылда мөмкинлекләр җитәрлек. 160 кешегә исәпләнгән мәрмәр ит җитештерү комбинаты эшли. Полиция бүлеге, малларны дәвалау урыны, почта, бакча, мәктәп, китапханә, кибетләр халыкка хезмәт күрсәтә. Мәктәптә ел саен ремонт эшләре үткәрелә, хәзерге вакытта ашханәсе яңартыла. Бакчага 12 сабый йөри. Мәктәпне быел 88 бала тәмамлаган. 2017 елда республика программасы нигезендә клубка капиталь ремонт ясалган. Иганәчеләр ярдәме белән ике мәчеткә 2 миллион сумлык төзекләндерү эшләре башкарылган. Узган ел республика программасы буенча авыл җирлеге бинасы төзелгән.

– Чүпне атна саен җыябыз. Килешәм, чүп савытлары булдырырга кирәк. Аны үзара салым акчасына куярбыз. Элек юллар саз иде. Әкренләп салып торабыз бит. Начар дип әйтеп булмый. Авылның ярты ягында – асфальт юл. Быел Совет урамына таш түшәргә җыенабыз, – ди Альберт Сафин. – Фельдшерлык-акушерлык пункты бар, яңасын салуны сорыйбыз. Бәлкем, киләсе елларда программага кертелер. Даруханәбез юк, анысы да кирәк. Су чишмәдән килә. Торбаларны ремонтлап торабыз. Җәй көне бакчага бөтен кеше берьюлы сиптергәндә, проблема туа. Торбаларны алыштыру өчен «Чиста су» программасына керергә кирәк. Ләкин бу җиңел түгел, проекты үзе генә дә миллионнар сорый. Үзара салым акчасын күп итеп җыярга туры киләчәк. Берсен ясыйсың, икенчесе кирәк. Халык сорап кына тора инде ул. Тик алар сүзендә дә хаклык юк дип әйтмим. Күгәрчен бит ул – зур авыл. Кечкенә генә түгел, зур авылларны да сакларга кирәк.

АТЛЫ ИЛГИЗӘР

ОЙМЯКОННАН МӘСКӘҮГӘ ТАБА БАРУЧЫ ДУГУЙДАН ЕВРОПАГА СӘФӘР ЧЫГУ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНА

Узган елның 5 мартында Якутиядә яшәүче Дугуйдан Винокуров һәм Мичил Неустроев, атка атланып, Оймяконнан Мәскәүгә таба сәфәргә кузгалалар. Максатлары изге. 11 мең чакрым юл узып, саха токымлы атларның көчен, ныклыгын тагын бер кат раслыйсылары килә. Юлның күп өлеше артта калган, әлегә илгизәрләр Татарстан җирендә хәл ала.

Бурятия, Тыва, Красноярск крае, Хакасия, Кемерево өлкәсе, Алтай крае, Казахстан, Чиләбе өлкәсе, Башкортстан, Татарстан һәм Чувашия – Дугуйдан һәм Мичил дүрт ат белән менә шушы маршрут буйлап Россия башкаласына барып җитәргә ниятләгән. Аларның теләген Рус географик җәмгыяте дә хуплый. Ләкин Мичил Себердән ары китә алмый. Атларының берсе имгәнә, икенчесе җан бирә. Шулай итеп, Новосибирскидан ары Дугуйдан ике аты белән үзе генә килә.

– Атка атланып, ил гизү турында 2018 елда ук уйлана башлаган идем. Ялгышмасам, Россиядә мондый сәфәр чыгучылар булмаган әле. Һәрхәлдә, XXI гасырда. Ә мондый озын юлны атын бер дә алыштырмыйча узучы дөньяда да юктыр әле. Ләкин төп максатым ул түгел. Якутиянең үз атлары барлыгын һәм ул атларның ни дәрәҗәдә көчле, чыдам булуын күрсәтәсем килә. Бу сәфәремне Саха (Якутия) автономиясенең 100 еллыгына багышлыйм, – дип сөйләде Дугуйдан Винокуров «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында.

Кызу дими, салкын дими

Саха токымлы атлар –70тән алып +40 градуска кадәр температураларга чыдам икән. Салкынга боланнар да чыдый анысы, әмма алар эссене авыр кичерә. Дугуйдан якут атларын башкорт һәм татар токымнары белән чагыштырып караган. «Безнекеләр кыска буйлы, базык, киң җилкәле була. Башкорт атлары да кыска буйлы, ләкин җилкәләре алай ук киң түгел. Татар токымлылар исә үзләре төз гәүдәле, үзләре озын буйлы була».

Ләкин якутлар атларны чыдам булулары өчен генә кадерләми. Элек-электән бөтен яшәешләре шуларга бәйле булган. Инде заманасы үзгәреп, тормышны техника яулап алса да, аттан башка яши алмыйлар. «Бездә үз атыңны башка берәүгә биреп торырга да ярамый, – ди юлчы. – Бу сәфәргә дә әтинең атлары белән кузгаласы идем, рөхсәт бирмәде. Боларын ал, барып җитәсеңләренә ышанам, диде».

Дугуйданның атларын озын, катлаулы юл да куркытмый.

– Көненә 45–55 чакрымлап юл узабыз. Хайваннарга авыр димәс идем. Авыр була башласа, туктап ял итәбез. Ә миңа авыр була алмый инде, утырып кына барам бит, – дип сөйли илгизәр. – Юлда төрле хәлләр була инде. Гел куркынычсыз сәфәр түгел бу. Трассага чыкмабыз, дисәк тә, кыш көне олы юл буйлап барырга туры килде. Машиналар бик күп бит хәзер, куркыныч иде, билгеле.

Яшь иптәш

Тамак ягы исә болайрак көйләнгән.

– Мин нәрсә табам, шуның белән тамак ялгыйм. Атлар да инде юлдагысын ашый. Хәзер рәхәткә чыктылар – үләннең куе, тәмле чагы. Ләкин Якутиянең көньягында кыенга туры килде. Беләсездер инде, узган ел бездә көчле янгыннар булды. Шул урыннарда атларга ризык бөтенләй юк иде, өч көн буе берни ашамадылар. Ә кыш көне артыбыздан атлар өчен азык белән машина барды. Туктаган чакта чатырда ял итеп алабыз, – ди Дугуйдан.

Зур шәһәрләрне дә читләтеп үтмәскә тырыша ул. Халыкның ничек яшәве, аның кебек сәяхәтчене ничек каршы алулары кызык икән.

– Татарстанда бик җылы каршы алдылар. Чәкчәк белән бавырсагыгыз бигрәк тә ошады. Шулай итеп каршы алулары һәм озатып калулары көч бирә, рухны ныгыта, – ди ул.

Сәфәренең калган өлешен Дугуйдан кечкенә улы Дархан белән узачак. «Атап, Татарстанга килде. 800 чакрымга гына түзә инде. 5 яшеннән бирле ат өстеннән төшми ул. Ауга да барганы бар», – ди кыю егетнең әтисе.

Максатына ирешеп, бу сәфәрдән исәнимин кайтып җитсә, Дугуйданның тагын да зуррак ниятләре бар. «Атка атланып, Европаны әйләнеп кайтасым килә», – ди ул. Хәерле сәфәрләр, Дугуйдан!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

vk.com

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖӘЙ КУЫП ҖИТӘРМЕ?

Эссе көннәр көтмәскә. Июль аен галимнәр дә, халык синоптиклары да шулай фаразлый. Аның каравы уңышка һәм көзнең беренче көннәренә өметләре зурдан.

Июльдә кояш чамасын белеп кенә җылытачак. КФУның метеорология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев шулай ди.

– Гидрометүзәк фаразларына да таянып, шуны әйтә алам: июль аенда һава температурасы +20...+21 градустан да артмаячак. Ләкин бу әле җәй салкын килә дигән сүз түгел. Һава торышы климат нормалары кысасында саклана. Явым-төшемнәр исә 60–70 миллиметрны тәшкил итәр дип көтелә. Ел башыннан исәпләсәң, Татарстан территориясендә явым-төшемнәр нормадан ике мәртәбә артыграк булды. 18 май көнне генә дә аларның суммасы 28 миллиметрны тәшкил итте. Мондый хәлнең 1983 елдан бирле күзәтелгәне юк иде, – ди белгеч.

Август аена шундый ук һава торышы фаразлыйлар. Ә менә көз башка елларга караганда җылырак, хәтта эссе булачак, ди белгеч.

Их, алмасы, чиясе...

Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче халык синоптигы Рәис Шәкүров та июльне яңгырлы килер дип фаразлый. Җәй башында ук, урыны-урыны белән рекордлы уңыш җыеп алу өчен барлык мөмкинлекләр дә бар, дигәннәр иде, ул да, шулай булырга охшап тора, ди.

– Әллә ни җылылар күренми. Иң югары температура +30 градустан да артмаячак, – ди ул. – Җәйнең болай килүе ашлыкка бик файдалы инде. Уңыш яхшы булыр, Алла боерса. Печән киптерү генә кыенрак. Анысын да инде, чапмасаң, үскән җиреннән череп ятачак бит. Аның каравы әнә ничек шаулап үсә! Чабып кына өлгер.

Башка еллар белән чагыштырып караганда, быелгы җәй ике атнага соңара икән.

– Башка елларда чәчәк ата торган культуралар Сабантуйларга кадәр үк шау чәчәккә күмелә иде. Ә быел басулар чуарлана гына башлады. Җәй соңаргач, көзнең беренче көннәре җылы киләчәк. Нәкъ ашлык җыя торган чор ул менә! – ди халык синоптигы.

Рәис абыйдан авыл халкының кәефен дә сорадык. Яңгыр яуган саен шөкер итәләр икән.

– Бәрәңгесе, кишере, чөгендере, кәбестәсе бар, аларга дым кирәк. Быел дым шәп, уңыш та яхшы булыр. Әле менә бакча җиләге өлгерде – учлап-учлап җыябыз. Ул да яңгырга кинәнде генә. Чия, алма, кура җиләге, карлыган уңышы да мулдан булачак. Алар чәчәк атканда кортлар күпләп очты, җылы булды. Инде хәзердән үк җиргә сыгылып-сыгылып төшкәннәр. Ә менә җир һәм каен җиләге аз булыр. Чәчәк аткан чаклары суык көннәргә туры килде шул, – дип сөйләде ул.

Июль аена халык сынамышлары

✓ Июль иртәсендә җылы яңгыр явып китсә, көндез һава торышы яхшы булыр.
✓ Әгәр июльдә билчән күп икән – суык кыш көтегез. Кузгалак күп булса, кыш җылы килер.
✓ Кич һава җылынып китсә, яңгыр галәмәте.
✓ Июльнең берендә кояш алтынсу-сары, алсу шәүлә белән байый икән, һава торышы яхшы булачак.
✓ Җәй уртасы – Питраудан соң үсемлекләр үсүдән туктый. «Питрау җитте – җәй үтте» дигән гыйбарә дә бар. Бу көнне яңгыр яуса, иген уңмый дип саныйлар.
✓ Егерме бишендә кырау булса, кыш суык килә.
✓ Июльнең соңгы көнендә көн эссе булса, декабрь суык килер.

ЙӨЗӘ АЛАСЫҢМЫ? КЕРМИ ТҮЗӘ АЛАСЫҢМЫ?

Җәйне никадәр генә зарыгып көтеп алсак та, елның-елында хәвеф-хәтәр, фаҗигаләре белән хәтердә уелып кала ул. Табигать бәла-казалары да, борчу-мәшәкате дә никтер аеруча күп була бу чорда. Ни кызганыч, суга бату очраклары да җәйнең алыштыргысыз өлешенә әверелеп бара.

Әҗәлдән качам димә

Ел башыннан бирле Татарстан сулыкларында 17 кешенең гомере өзелгән. Шуларның унысы коену сезоны башлангач вафат булган. Чагыштыру өчен: узган елның шушы чорында республика сулыкларында 23 кешенең гомере өзелгән булган. Быел җәй башлану белән батып үлгән ун кешенең өчесе – балалар.

Балаларның суга батуы турында беренче ачы хәбәрне 17 июнь көнне ишетергә туры килде. Дүрт үсмер, Чаллыдагы «SunDale» комплыгы буйлап йөргәндә, су эчендә урнашкан утраучыкка таба йөзеп барырга уйлыйлар. Әмма икесе анда барып җитә алмый, агып китә. Бәхеткә, аларның берсе йөзеп чыга ала. Икенчесе төпкә бата. Егетнең мәетен ярдан 50 метр ераклыкта табып алалар.

Чирмешән районының Күтәмә авылында яшәүче 9 яшьлек малайга да балыкка киткән җирдән исән-сау әйләнеп кайтырга язмаган. Иптәшләре, шактый озак балык тотканнан соң, өйләренә таралыша. Малай исә утырып кала. Кичке якта аның туганнары чаң суга. Бөтен авыл белән эзләргә керешәләр. Иң элек яр буенда киемнәрен табып алалар. Күтәмә авыл җирлеге хезмәткәре Алена Михляева сүзләренә караганда, кичке якта авылның «Ватсап» төркемендә бала югалу турында хәбәр тарала. Малайны авылдашлары, полиция һәм янгын сүндерү хезмәткәрләре эзләргә чыга.

«Ирләр колгалар белән елга төбенә төртә-төртә эзләде. Ике сәгать буе эзләүнең нәтиҗәсе булмады. Авылыбыз егете баланың гәүдәсен ярдан бер метр ераклыкта 1 метр тирәнлектә табып алды. Ул вакытта коткаручылар килеп җиткән иде инде. Су коенырга теләгән, күрәсең. Аның мәетен судан чыгарулары әле дә күз алдымда. 9 яшьлек сабый бит ул. Бик зур кайгы. Бу хәсрәттән әле дә айный алмыйбыз», – ди Алена Михляева.

Саба районының Кече Шыңар авылы халкы да – бүген тирән кайгыда. Бернечә көн элек шушы авыл егете Динар Хөсәенов Миңгәр авылы буасында батып үлгән. 18 яшьлек егетнең иптәшләре белән кич чыгып киткән җирдән кире әйләнеп кайтмавына якыннары әле дә ышана алмый. Авылның фельдшеры Рузилә Мөхәммәтова әйтүенчә, бөтен авыл кара кайгыда.

Яшь гомере өзелгән кичтә Динар иптәшләре белән башта күрше Тимершык авылына клубка бара. Аннары яшьләр Миңгәр авылындагы буага юл тота. Ул авыл уртасында урнашкан. Рузилә ханым сүзләренә караганда, анда балыкчылар кереп балык тота торган зур сал бар. Коену сезоны башлану белән, яшь-җилкенчәк яр кырыена бәйләп куелган шушы салны ычкындырып җибәрә икән. Егетләр килгәндә, сал буа уртасында йөзеп йөргән. Алар аны алып чыкмакчы булганнар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Динар бик акыллы, тырыш, сабыр, тыныч егет иде. Бик тәртипле гаиләдә үсте. Быел КАИның радиотехника факультетында беренче курсны тәмамларга тиеш иде. Тик торуны белмәде. Әле үләсе көнне дә, Казаннан кайтып, озак итеп печән чапкан. Мунча кереп чыккач, кич чыгып тормыйм дип тә уйлаган булган үзе. Әмма иптәшләре чакыргач, каршы килмәгән. Әҗәлдән качып котылып булмый шул. Бик кызганыч», – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә Рузилә Мөхәммәтова.

Динар баткан урында тирәнлек – 6 метр. Егетнең аягын көзән җыерган дип фаразлыйлар. Күреп торабыз: быелгы җәй артык җылылары белән иркәләргә охшамаган. Кичкә таба су керерлек түгел, киресенчә, урамга калынрак киенеп чыгарга туры килгән көннәр дә булды. Ә бу көнне яшьләр кичке тугыздан соң су кергән. Өстәвенә, Миңгәрдәге бу буада астан чишмә бәреп тора, ди авыл халкы. Андый урында суның җылынычагы юк, билгеле.

Югары Ослан районының Ключище авылы янындагы елгада батып үлгән 13 яшьлек кызны да аңәле иптәш кызлары белән йөреп кайтырга чыкканда сагалап торган. Күпер аша узып барганда, кызлар суга сикереп карарга булган. Әмма аларның икесе генә йөзеп чыга алган. Хәтерләсәгез, әле бернечә көн элек кенә Казандагы «Миллениум» күперенннән сикергән бер кыз баланың да гомере өзелде.

Белдерү элеп котыла

Татарстанның кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы Юрий Венедиктов фикеренчә, балаларның суга батуында иң беренче чиратта ата-аналар үзләре гаепле. «Судагы фаҗигаләрнең барысы да ата-ананың балага игътибар итмәве, аларның ни теләсә, шуны эшләп йөрүе аркасында килеп чыккан. Шуңа күрә ата-аналарга тагын бер кат мөрәҗәгать итәсем килә: балаларны су янына үзләрен генә җибәрмәгез. Үз башларына үзләре хуҗа булып йөрмәсеннәр. Алар мәктәп яны, сәламәтләндерү лагерьларында яки туганнары, якыннары карамагында ял итәргә тиеш», – ди белгеч.

Юрий Венедиктов сүзләренә караганда, сезон башланганнан бирле теркәлгән батып үлү очраклары, нигездә, суда кешенең хәле авыраю, рөхсәт ителмәгән урыннарда су коену аркасында килеп чыккан. Рәсми саннарга күз салсак, бүген республикада 50 комлык исәпләнә. Әмма бүген шуларның 34е генә эшли. Шуларның 24е – Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә, Зәй, Лениногорск, Бөгелмә, Алексеевск, Яшел Үзән, Лаеш, Тәтеш, Яңа Чишмә, Кама Тамагы, Апас һәм Спас районнарында, калган сигезе ял базаларында эшли. Венедиктов сүзләренә караганда, быел республика районнарына яңа комлык төзү һәм төзекләндерү өчен барлыгы 24 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Әмма бу акчаны тиешле максатта тоткан районнар саны бармак белән генә санарлык. Әйтик, Әлки, Актаныш, Әтнә, Балтач, Теләче, Кайбыч, Менделеевск, Чүпрәле, Питрәч, Сарман, Саба, Чирмешән районнарында андый комлыклар бөтенләй юк.

– Республиканың ун районындагы комлыкларда әле дә коткару постлары булдырылмаган. Лениногорск районындагы Менделеев урамы буендагы инеш янында, башкаланың Гаврилов урамындагы комлыкта да юк алар. Төпчекнә башласаң, килешү төзеп булмый, комлык ачу өчен урын юк кебек һаман да шул бер үк сәбәпне ишетәсең. Болар бар да – район дәрәҗәсендә хәл итеп булырлык мәсьәләләр бит. Халыкның ял итү урыннарын тәртипкә китерәсе урынга, «Су коену тыела» дигән такта-белдерү элеп куялар да шуның белән шул, – ди Юрий Венедиктов.

Татарстанның кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы гадәттән тыш хәлләр буенча комиссиянең чираттагы утырышында Татарстан Премьер-министры урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллинга бу уңайдан мөрәҗәгать белән дә чыкты. Аерым алганда, комлыклар булдыруга бүлеп бирелгән акчаның вакытында һәм максатчан рәвештә файдаланылуын контрольгә алуны сорады ул.

СУГА БАТУЧЫНЫ КОТКАРГАНДА ИСТӘ ТОТАРГА КИРӘКЛЕ КИҢӘШЛӘР

✓Еш кына суга батучы, куркудан, үзе дә сизмәстән, коткаручыны да үзе белән су астына өстери башлый. Шуңа күрә ул сиңа ябышмасын өчен, батучыны арткы яктан, иң яхшысы чәченнән эләктереп алырга кирәк.

✓Суга батучы сиңа ябышкан очракта, «тозак»тан ычкыну өчен, батучы белән бергә суга чумарга кирәк. Бу очракта ул, су өстендә калырга теләп, коткаручысын җибәрәчәк. Батучы төпкә төшеп киткән булса, коткаручы, суга чумып, батучының кулыннан, култык астыннан яисә чәчләреннән эләктерергә һәм, су төбеннән ныклап этенеп, аяклар һәм буш кул белән эшләп, су өстенә йөзеп чыгарга тырышырга тиеш.

✓Ярга чыккач, суга батучыга беренче ярдәм күрсәтелә. Зыян күрүче аңында булса, йөрәк тибеше тоемланса, аны, башы түбәндә булырлык итеп, каты коры урынга яткырырга кирәк. Аннары аның өс киемнәрен салдырып, тәнен кул яисә коры сөлге белән яхшылап ышкырга. Кайнар эчемлек биреп, җылы одеялга төрергә дә онытмагыз.

✓Зыян күрүче аңында булмаса, әмма пульсы һәм сулышы сизелгән очракта, башын артка җибәреп, аскы теш казналыгын тартып, башы аска төшеп торырлык итеп яткырырга һәм бармак белән авыз эчен чистартырга, тәнен корытып сөртергә һәм җылытырга кирәк.

✓Аңында булмаган, сулышы сизелмәгән кешенең иң элек сулыш юлларыннан суны чыгарырга тиешбез. Моның өчен ярдәм күрсәтүче зыян күрүчене эче белән үзенең тездән бөгелгән аягы өстенә куя, бер кулы белән калак сөякләре арасына баса, икенче кулы белән, маңгаеннан тотып, башын күтәрә. Бу хәрәкәтләр 10–15 секундтан артмаска тиеш. Аннары судан чыгарылган кешегә тиз арада ясалма сулыш алдырырга кирәк. Сулыш һәм йөрәк тибеше булмаганда, ясалма сулыш алдыруны йөрәккә массаж белән аралаштыру мөһим.

✓Беренче ярдәм күрсәткәннән соң, суга батучыны кичекмәстән хастаханәгә озатырга кирәк.

Һәр секунд исәптә

Тәҗрибәле водолаз Руслан Брагин су янында үзеңә генә түгел, әйләнә-тирәдәге кешеләргә карата да икеләтә игътибарлы булырга кирәк дип саный. «Күпләр «Коткарыгыз!» дип кычкырган очракта гына кешегә ярдәм итәргә кирәк дип уйлый. Әмма бу – зур хата. Еш кына бата башлаган кешенең ярдәм сорап кычкырырга вакыты да, мөмкинлеге дә булмый. Суга батучы кеше, кычкырыр урынга, мөмкин кадәр күбрәк сулыш алырга тырыша. Шуңа күрә суга кереп киткән кешене беркайчан да күздән югалтырга ярамый», – ди Руслан Брагин.

Коткаручы сүзләренә караганда, төпкә китәр алдыннан кеше бернича тапкыр батып калка әле. Рәсми саннарга ышансаң, беренче минутта суга батучыларның – 90 процентын, 6–7 минуттан соң фәкать 1–3 процентын гына коткарып калырга мөмкин. «Суда алты минуттан да озаграк тормаган кешене коткарып калып була әле. Аннары инде аның аңы томалана. Балаларда ул аеруча тиз бара. Шуңа күрә суга батучыны коткаргында һәр секунд кадерле. Су төбенә киткән кешене инде коткарып булмаячак», – ди Руслан Брагин.

Билгеле булганча, суга бату очраклары, гадәттә, кешенең суда паникага бирелүе, тәнен көзән җыеру яки исерек килеш су коену аркасында килеп чыга. «Су коенганда көзән җыерса, баш бармакны тотып, аякны мөмкин кадәр өскә күтәрергә кирәк, – ди Руслан Брагин. – Балтырны көзән җыерган очракта да су астында шундый хәрәкәтләр ясарга тырышыгыз. Ботны көзән җыерган очракта, киресенчә, аякны тездән бөгеп, үзеңә таба тартырга кирәк».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РӨСТӘМ НАСЫЙБУЛЛИН:
«ТАБИБЛАР ДА УЛ КАДӘР УКЫМЫЙ»

Җырчы Салават Фәтхетдинов Рөстәм НАСЫЙБУЛЛИН турында: «Түбән тавыш авыр йөк кебек, ул «неповоротный» була. Рөстәм, кагыйдәләрне бозып, түбән тавыш белән дә бормалар ала», – дигән иде. Хикмәтле тавыш иясе белән эстрада хәлләре, җырчылар һәм җырлаучылар, сәнгать белән тормыш алып бару һәм башка мәсьәләләр турында сөйләштек.

:: Тавышың белән аерылып торсаң да, холкың белән аерылып торырга яратмыйсың бугай. Кайбер җырчылар аена егермешәр концерт куйганда, синең сольный концертларың күренми.
– Концертлар оештыру өчен дә өлгереп җитү кирәк. Шул юнәлештә эш бара инде. Тавыш белән аерыламдыр, холыкка әрсезлек җитмидер.

:: Һәрхәлдә, эстрадада түбән тавышлы җырчылар юк дәрәҗәсендә. Күбесе тенорлар. Шулайдыр бит?
– Тенорлар дип тә әйтеп булмыйдыр аларны. Чөнки бер нота белән икенче нотага күчкәндә, җырчының аерым бер диапазоны, тавыш киңлеге була. Ә безнең эстраданы алсак, бу киңлек йөз җырчының икесендә генә бар. Хәтта ае буе концерт куючыларда да киңлек бар дип әйтеп булмый.

:: Җырчы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?
– Үз эшенә бирелгән булырга тиеш. Әйтик, чыгыш билгеләнгән икән инде, чирлеме син, кайгың бармы – бернигә дә карамый сәхнәгә чыгып җырларга кирәк. Моның өчен үзеңне даими формада тотасың. Бу инде – җырлау техникасын белү, җиде кат тиреңне чыгарып әзерләнү дигән сүз.

:: Әмма, укымыйча да җырчы булып була, диләр бит. Алай түгелмени?
– Җырчы булып булмый, җырлаучы булып була. Беренчесен сайлаганда, кимендә 5–6 ел укырга кирәк. Мин 9 ел музыка белеме алдым. Бу – музыка мәктәбе, музыка училищесы, консерватория. Табиблар да ул кадәр укымый.

:: Шулайдыр. Тик халык укыган җырчыларны түгел, укымаганнарны тыңлый. Элек үзешчән дип атала иде алар, хәзер андый бүленеш бетте дә бугай инде.
– Халык тыңлый дип сәхнәгә шортиктан чыгып сикереп йөреп булмый инде. Безнең дә тамашачыбыз бар. Алар күп түгел, ләкин бар. Киләчәктә дә булачак. Иң сөенечлесе: ул тамашачы арасында яшьләр күп. Алар булганда профессиональ сәнгатьнең киләчәге алай ук өметсез түгел.

:: Әти-әниең җырчы булуыңа ничек карый?
– Әти Нурлат шәһәрендәге музыка мәктәбенә алныялны белмичә йөртте. Күрәсең, кечкенәдән минем сәләтне күреп алгандыр. Конкурсларда катнашсам, репетициягә көн саен бара идек. Ә безнең авыл район үзәгеннән 20 чакрым читтә. Әти-әни, бәлкем, минем җырчы булуыма ышангандыр да, ә мин үзем алай уйламадым. Тавышым башта үземә бик ошап җитми иде.

:: Җыр белән тормыш алып барып буламы?
– Хәзерге вакытта тормышымны җыр белән алып барам. Ул мине дә, гаиләмне дә ашата, киендерә.

:: Җырчыларның төрле бизнесларга кереп китүенә ничек карыйсың?
– Һәркемнең – үз эше. Челтәрле бизнес дигәне миннән булмас иде. Башка бизнес турында уйлап карарга була. Әйтик, менә мин – аграр университетның икътисад факультеты студенты. Казанга 2010 елда килгән идем, шул елдан бирле укыйм да укыйм. Инде өч балам бар, ә мин – һаман студент. Киләсе елга дипломлы белгеч булам, Алла боерса. Ник дигәндә, ир-егеткә җир һөнәре дә кирәк. Һаваларда гына очып йөреп булмый бит. Ә укырга керүем үзеннән-үзе килеп чыкты. Режиссер Роберт Галиев аграр университетта төрле чараларны бик еш үткәрә иде, җае чыккан саен чыгыш ясарга мине дә чакырды. Тамашыларга мине гел «безнең студент» дип игълан итәләр иде.

Рөстәм Насыйбуллинның шәхси архивыннан

Консерваторияне тәмамлаган елны университетның ректоры: «Кеше алдап йөреп булмый, әйдә укырга кер», – дип чакырып алды. Бу очракка мин шат кына. Дөнья куласа, бу һөнәрнең дә кирәге чыгып куюы бар.

:: Репертуарыңда күбрәк классик, ретро җырлар. Алар белән танылып буламы? Халыкка «ярата, яратмый» ише җырлар күбрәк ошый кебек.
– Сез әйткән «ярата, яратмый»ны җырлаучыларның да бит репертуарлары ретро җырлардан була. Элвин Грей да шундый җырлар белән танылды. Мәгънәне беркемнең дә киреексезгә чыгара алганы юк әле.

Үземнең җыр дигәндә, мин Айдар Фәйзрахмановның «Олы юл әйтте» циклындагы җырларны күз уңында тотам. Ул махсус минем өчен җырлар иҗат итте. Алар арасыннан үземнең визит карточкам дип Айдар абыйның Сания Әхмәтҗанова сүзләренә иҗат иткән «Тәгәри тормыш арбасы» җырын аерып әйтер идем.

> Сәхнәгә чыккач, тыңлаучыга ниндидер хис яки фикерне җиткерәсе килә. Бу классик, ретро җырларда бар. Махсус үзем өчен язылган җырлар да шушы ук таләпләргә туры килә. Кем өчендер алар «скучный» җыр саналадыр. Әмма тыңлый белгән кеше алай дип әйтмәс.

:: Сине төрле фестивальләрдә, бәйгеләрдә күрә идек. Аларда гаделлек бармы?
– Бу сорауны ни өчендер бик еш бирәләр. Икеләнергә урын калдырмаслык итеп җырлыйсың икән – җиңәсең, юк икән – юк инде.

:: Эстрадада, синеңчә, төп проблема нинди?
– Мөгаен, система булмаудыр. Элек худсоветлар булганда сүзгә дә, көйгә дә, башкаручыга да бәя бирелгән. Хәзер дә шулай бәяләнсә, начар булмас иде.

:: Төп юнәлешең нинди?
– Минем юнәлеш – эстрада белән академик сәнгатьнең уртаклыгын саклау. Классик әсәрләр генә дә башкарасы килми, эстрада юлын сайлап, саллы әсәрләрдән дә баш тартасы килми. Тагын шунысы да бар: без дә җырламасак, күпме җыр онытылыр иде. Әйтик, мин быел Җиңү җырларыннан торган концерт куйдым. Бик күпләр Җиңү җырларының татарчалары барлыгын белмәгән дә икән. Бу концерт табыш китерә торган түгел, ул күбрәк пропаганда өчен эшләнә. Киләсе елга Казанда гына түгел, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә дә шушы концертны куясы килә.

:: Әгәр дә җыр өлкәсеннән китсәң, нинди һөнәрне сайлар идең?
– Башка һөнәр турында уйлап караганым булмады. Шулай туры килә икән, эшсез калмыйсыңдыр инде ул. Узган атнада авылда койма тотып килдем, шәп эретеп ябыштыручы була аламдыр. Һәрхәлдә, югалып калмабыз. Шуның өчен төрле өлкә белән кызыксынам, укыйм.

:: Җырчы булу – һөнәрме?
– Авылда да, һаман җырлап йөрисеңме, эшкә урнашмадыңмы әле, дип сорыйлар. Җырчы булу – һөнәр ул, һәм җырлау җиңел эш түгел. Шактый маңгай тире ага анда. Мәсәлән, «Отелло» операсын куйганда, төп партияне башкарган Хәйдәр Бигичев 6 килога ябыга торган булган.

:: Китап укыганда яки фильм караганда елаганың бармы?
– Бар, әлбәттә. Читтән, бәлки, каты холыклы күренәмдер, чынлыкта алай түгел. Әле менә кызым әбиләрендә кунакта калган иде. Иртән телефоннан сөйләшеп алдык. «Әти, кайчан кайтасыз инде?» – ди. Ул шулай дигәч, күзгә яшьләр килде. Балалар сагындыра. Без аны зур кыз дибез инде, зур дигәненә дә биш яшь кенә бит әле.

:: Өйдә нинди телдә сөйләшәсез?
– Әлбәттә, татарча. Ул табигыйдер инде. Урысчабыз начар безнең *(көлә)*.

– Балаларың синең юлны сайласалар, каршы килмәячәксеңме?
– Үзем күргән дә җиткән, минем кебек интекмәсен дип, балаларын тыйган артистлар барын да беләм. Таланты күзгә бәрелеп тора икән, ничек тыясың? Ходай салган сәләт бит ул.

:: Соңгы укыган китабың нинди?
– Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре». Шул җыентыкка кергән шигырьләрнең шактыена композитор Рөстәм Яхин көй язган булган. Шул җырларны өйрәнеп, аннары яздырып, фондта калдырасым килә.

:: Шунысы бар: бу җырлар табыш китерә торган түгел.
– Бөтен нәрсәне дә акча белән үлчәп булмый бит. Миңа күбрәк мөнәсәбәт кадерле. Кайчак, бер генә җыр җырлап кит әле, дип чакыралар. Бер җыр өчен генә түли алабыз, дип тә искәртәләр. Бер әзерләнәсең икән инде, җыр саны белән килмисең. Яраталар икән, миңа җырлау авыр түгел. Өчне дә, алтыны да җырлый алам.

:: Банкетларда, туйларда чыгыш ясыйсыңмы?
– Алай эшләргә дә туры килә. Җәй көне концертлар бетә, шабашкалар алабыз. Бер караганда, бу да – үзеңә реклама бит. Туйда сине ишеткән кеше концертыңа да килергә мөмкин. Аннан килеп, мин туйларда да мәгънәсез җырлар җырламыйм.

:: Нәселегездә синең кебек көчле тавышлы җырчылар бармы?
– Юк, бер мин генә җырлыйм. Әти әйтүенчә, бабай мәҗлесләрдә җырлый торган булган. Бабай бакыйлыкка күчеп, кырыгынчы көне җиткәч, мин туганмын.

:: Бүген күңелгә нинди җыр килә?
– Мансур Мозаффаровның «Саумы, кояш» җырын көйләп килдем әле. Көн матур, кәеф әйбәт.

:: Җырның авторын әйтеп сөйләшүең дә кызык. Күп җырчылар авторларны оныта.
– Менә анысы начар. Бу – музыкаль белем булмау бәласедер.

:: Радиодан сирәк ишетеләсең, телевидениедән күренмисең дә диярлек.
– Җырны ротациягә бирергә мөмкинлек юк әлегә. Анда бик зур суммалар сорала. Клип төшерергә ният бар. Аңа Нурлат районы ярдәм итә. Мине үскән җиремдә беләләр, ярдәм итәләр. Менә анысы өчен Нурлат районы хакимиятенә рәхмәт әйтәсем килә. Андый мөгамәлә бик сирәк районнарда гына бар ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ГҮЗӘЛ ӘДҺӘМ

АЛСУ ТӘРӘЗӘ

(ХИКӘЯ)

Машинасын ярата иде Дамир. Менә бүген дә юеш асфальт төсендәге «Мазда»сына иркәләп күз салмый түзә алмады, аңа гына күңеле канәгать калмыйча, бармакларын уйнатып, «тимер айгыр»ын назлагандай сыпырып та куйды ир. Шәп тә соң машинасы! Ә иң шәбе – кредит түләнеп беткән! Үзенеке! Үз машинасы хәзер!

Шуннан соң ул фатирының тәрәзәсенә күтәрелеп карады.

Төн үзенекен иткән: «мегаполис» дип аталган ундүрт катлы йорт та татлы йокыга талган икән... Якты тәрәзәләр дә анда-санда гына күренә. Сигезенче каттагы ялгыз алсу тәрәзә исә, Дамирның тынычлыгын бозып, шомландырып чекерәеп тора. Нәкъ менә чекерәеп! Куралмый ул шул алсу тәрәзәне! Туйды! Гарык булды! Шул алсулыкка уралган Фәридә, аның йокысызлыктан талчыккан күзләре ирнең җен ачуын чыгара. Акланырга, алдашырга һәм ялганларга мәҗбүр иткән шул караштан тизрәк котыласы килә аның. Китәчәк! Иртәгә үк Самира янына күчәчәк ул. Болай да күп түзде...

чыгуына да сәгать ярым гына вакыт үткән иде.

Тәлинкәсенә төбәлеп, кашык белән ашын болгатып, шактый утырды ул. «Кызыл аш» пешергән икән Фәридә. Дамирның яраткан ашы! Фәридә аш-суга оста, борщы ашап туймаслык була иде...

Ашны бер капты... Тәмен тоймады. Башында ашау кайгысымыни?! Теге мөһим сүзне башларга кирәк лә!

Тагын бер кашык ашны бугазына шудырды...

– Сөйләшәсе бар иде...

Чәй ясап торган Фәридә, «шык» итеп, газ плитәсенә чәйнеген куйды. Шул тавышка дертләп китте ир. Үз булдыксызлыгына үзе үртәлеп калтырап куйды ул, җебегәнлегенә, теге мөһим сүзне әйтә алмый сузып йөрүенә отыры ачуы кабарып, кашыгын чытырдатып кысты.

«Өзәргә! Хәзер үк араны өзәргә кирәк!»

Ярый әле Фәридәсе аның күз алдында басып тормый. Каршысында булса, теге мөһим сүзне әйтергә, тәгаен, көче җитмәс иде Дамирның. Хатынының карашын бөтен җилкәсе белән тойган, сиземләгән хәлдә сүз башлады ул:

Алсу пәрдә артындагы Фәридә... Һәм андагы ике малай... Менә шулар богаулап тора аны! Югыйсә әллә кайчан назлы Самираның кочагында эреп, рәхәткә тиенәсе ир ләбаса! Фәридәсе – Фәридә... Аннан китү бер генә күзәнәген дә дерләтмәс кебек, чөнки хисләр инде күптән суынган, сүнгән, хатынының кайчандыр башны әйләндергән чәч исе дә хәзер инде аның күңелен генә болгата иде.

Улларының олысын ярата иде Дамир. Ринат исемле ул. Үз каны, нәкъ үзе кебек кылдай каты кара чәчле ябык малай!

«Туктале, ничә яшь соң әле аңа?»

Ир сискәнеп куйды.

«Әллә яшен дә белмиме? Хәзер, хәзер... Быел укырга керде... Димәк, җиде тулып киткән! Шуны да белмәскә!»

Ватанны саклаучылар көнендә туды малай. Анысын бик яхшы хәтерли Дамир. Беренче бала бит! Җитмәсә – малай! «Армиядә булмасам да, миңа бүләкнең шәбе эләкте!» – дип мактанып, малай тәпиен юып йөрүен ничек онытсын ди! Күршеләре Наилә белән бер көнне бәбиләде Фәридә. «Бракодел!» – дип, бирде кирәген Дамир ул чакта күршесе Саматның. Ә анысының (тиле дими, ни дисең инде!) исе дә китмәде, авызын ерып шатланып йөрүен белде. Имеш, кызы бар...

Ә менә икенче малаен – Данилны үз итә алмады Дамир. Исеме үзенекенә аваздаш булса да, бер тамчы да охшамаган иде ул әтисенә. Әллә нинди елак бер чирләшкә шунда. Шул малай туганнан бирле, өйдә тәртип бетте, тынычлык китте, йокы качты. Шуның елавыннан гарык булган Дамир мөмкин кадәр соңарып кайтырга гадәтләнде. Хәзер инде Данил да өч яшен тутырып, бакчага йөри башлады... Еламый да кебек... Тик Дамир гына аны ярата, якынайта алмады. Күңеле нечкәреп, кочакламакчы булып үрелгән мәлләрендә дә малай аңа якын килми, тибенә, чәбәләнә башлый. Әллә нинди кыргый бер бала шунда...

...Фәридә чынлап та йокламаган иде.

– Ашыйсың киләме?

– Килә...

Чынлыкта Дамирның тамагы тук, Самира-сылу белән ресторанда сыйланып

– Безгә... аерылышырга кирәк...

Нидер «чык» итте. Шул чыкылдаудан ул сискәнеп куйды. Әллә бал кашыгы чынаякка бәрелдеме? Ир хатынына карамый гына сүзен дәвам итте.

– Мин башканы яратам... Аның белән яшәргә телим...

Фәридә дәшмәде.

Дамир нидер көтте. «Я, нигә дәшми инде ул? Еласын, кычкырсын иде, ичмасам!»

Озын бер гомергә тиң вакыт үткәндәй тоелды иргә. Озын бер гомер! Шундый сәер, шыксыз тынлыкны ишек тавышы бүлде. Малайлар бүлмәсенең ишеге шулай ыңгырашып ачыла иде.

«Әллә улларының берсе уянып чыкканмы?»

Дамир борылса, шаккатты. Бүлмәдә ни балалар, ни Фәридә юк иде. Ничек шулай шыпырт кына чыгып китә алган ул? Бер тавышсыз малайлар янына үткән, инде ишекне дә ябарга өлгергән...

«Сәер... Бик сәер... Аңламассың бу хатын-кызны! Ирен шулай берсүзсез генә ятларга биреп җибәрергә риза микәнни Фәридә?»

Күкрәген нәрсәдер тырнап куйды: үзенең кирәксезлеген тою ирлек горурлыгын җәрәхәтләп узды. Шулай да ул тиз тынычланды.

«Главное – эшләнде: теге сүз әйтелде. Фәридә аны ишетте».

Ир кузгалды, утны сүндереп, йокы бүлмәсенә үтте. Ул яратмаган теге «алсулык» та югалды. Әллә диварларга сыланып тоныклануы гынамы? Өстәлдә мөлдерәмә тулы, сөтле чәйле ялгыз чынаяк калды.

...Тагын бер атнадан, Самира белән бергәләп, Кара диңгез буена китәргә тиеш иде ул. Ундүрт көнгә! Билетлар күптән алынган, путевкасы да кулда. Чемодан тутырасы гына калган иде. Ә диңгез буенда – иң матур чак! «Бархатный сезон!» Самирасы шулай теләде: аның наз тулы җаны эссене күтәрә алмый, шикәрдәй ак нәфис тәне дә кояшның кайнар нурларын яратып бетерми, имеш. Сәяхәткә киткәнче, Фәридә белән араны өзеп, кушылып яши башлау иде исәпләре. Дөрес, Самираның фатиры аларныкыннан шактый кайтыш – ике бүлмәле хрущевка.

Дамир елмаеп куйды:

– Зато ипотекасын түлисе юк!

Ундүрт этажлы яңа йортның сигезенче катында урнашкан өч бүлмәле бу фатирга алар инде биш ел буе түләп торалар. Ипотека! Түләү суммасын ел саен арттыра баралар, тик очы-кырые гына күренергә җыенмый. Аерылышканда фатирны Фәридәгә калдырырга уйлый Дамир. Шулай планлаштыра. Үз балаларыннан фатирны да тартып алырга сез аны кем дип уйлыйсыз! Андый ук мәрхәмәтсез түгел лә ул! Яшәсеннәр шунда. Фәридәсе югары белемле, ипотека түләрлек җаен табар әле. Ә менә «Мазда»сы – «тимер айгыры» аңа калачак! Фәридә моңа каршы булмас, өч бүлмәле фатирны калдырганга шатланып риза булыр әле.

Фәридә белән Дамирның танышулары кызык кына булды: «автошкола»да бергә укыдылар. Икесе дә яшь, икесе дә тулай торакта яши, йөреп киттеләр. Укыганда Фәридәнең зирәклеге шаккатырды. Машинаны биш бармагы кебек белә, фәлән ел руль артында утырган диярсең! Дамирның гаҗәпләнүенә көлеп кенә җавап бирде ул:

– Шофер кызы ла мин!

Имтиханны да иң беренче булып тапшырды Фәридә, Дамирга да ярдәме тиде әле. Әмма үзләре машиналы булгач, рульгә якын да килмәде:

– Яраткан ирем янәшәсендә утырып йөрү миңа күбрәк ошый! – диде.

Менә болай планлаштыра Дамир: «фатир – сиңа, ә «тимер айгыр» – минеке!»

...Иртәнге ашны ашап, иң беренче булып эшкә китәргә гадәтләнгән Дамир малайлар тавышына уянып китте. Сәгатькә күз салса – сигезенче ярты!

«Булдырган Фәридә! Уятмаган! Үзенчә үч алуы инде».

Дамирның эше сигездә үк башлана. Соңга калмасын тагын! Сикереп торуы булды, тиз-тиз юынып, кухняга үтте.

– Фәридә! Капкаларга берәр нәрсә бир дә...

Фәридә күренмәде.

– Фәридә дим!

Җавап ишетелмәде. Кухня буш иде. Өстәл өстендә ризык-фәлән күренми. (Кайда йөри бу хатын?) Күзе өстәлдә яткан кәгазьгә төште. (Нинди кәгазь ята монда?) Алды. Күз йөгертеп чыкты. Аңламады. Нәрсә соң бу? Тагын бер кат укыды. Барыбер төшенеп җитмәде. Фәридәнең түгәрәк-түгәрәк «а», «д», «б» хәрефләре башта чуалып буталдылар да аннан мигә барып җитәлми әүмәкләшеп беттеләр. Бераздан гына түгәрәк хәрефләр рәт-рәт булып тезелде...

«Дамир! Яраткан кешең белән яшә. Юлыңа аркылы төшәргә теләмим. Мин китәм. Бәхетле бул! Малайлар әлегә синең янда кала. Фәридә».

Ир телсез калды.

Бер тын, таш сындай, саташулы-уяулы катып торганнан соң, ул аңына килде сымак. Тик баш эшләми: анда нәрсәдер кайный, болгана. Бу халәттән ул бик тиз чыкты, дөресрәге, аны улы уятты.

Ринат аңа килеп сыланды:

– Әни кайда соң?

Дамир шунда аңына килде. Нидер эшләргә кирәк иде.

– Хәзер... хәзер...

Кулына телефонын алды, ашыга-ашыга Фәридәнең номерын җыйды:

«Недоступен!»

Тагын, тагын җыйды!

– Не-дос-ту-пен!!!

Дамир үзен-үзе белештерми кычкырып җибәрде:

– Фәри-дәәәә!

Дәвамы бар >

Шигърият

Әнгам АТНАБАЕВ

***

Ромашкалар, гашыйк ромашкалар
Хәтерләтте яшьлек елларын.
Мин аларның керфекләрен өзеп,
Ул ярата, диеп юрадым.

Ромашкалар, ромашкалар
Алдамасын, мине аңласын.
Ромашкалар, ромашкалар,
Алдамасын, безне аңласын.

Юлларына чыгып, кулларына
Йөрәгемне салдым – алмады.
Мин яраттым, ә ул яратмады –
Ромашкалар мине алдады.

Ромашкалар, ромашкалар
Алдамасын, мине аңласын.
Ромашкалар, ромашкалар,
Алдамасын, безне аңласын.

Ромашкалар, гашыйк ромашкалар
Юлларыңа үссен тезелеп.
Һәм аларның соңгы керфекләре
Ярата дип төшсен өзелеп.

Ромашкалар, ромашкалар
Алдамасын, мине аңласын.
Ромашкалар, ромашкалар,
Алдамасын, безне аңласын.

СИН ЯНМЫЙСЫҢ ХӘЗЕР...

Бүген килеп, миңа сөйләдең син:
Минем өчен утта янгансың,
Минем баскан эзләремә басып,
Озак кына арттан баргансың.
Ә аннан соң...
Өмет өзеп, торып калгансың.

Ә мин, юләр, игътибар да итми,
Гамьсез генә ары киткәнмен.
Мәхәббәтне җиргә карап түгел,
Йолдызларга карап көткәнмен.

Минем хәтта батырчылык җиткән
Син елаган чакта көләргә.
Син янгансың, дөрләп янгансың да
Әйләнгәнсең азак күмергә.

Шул турыда миңа сөйләдең син.
Син дә – синсең, мин дә – мин һаман.
Аерма тик бары шунда гына:
Син янмыйсың хәзер, мин янам!

***

Рәхмәт, дөнья! Миңа, ни теләсәм,
Сусаганда шуны эчердең.
Туган якның юкә балдай татлы
Һаваларын эчеп исердем.

Башларыма яңгыр суы сибеп,
Колагымнан тартып үстердең;
Язлар җитсә, каеннарны тишеп,
Ширбәт суын эчеп исердем.

Рәхмәт, дөнья!
Озын юлларыңның
Коры тузаннарын эчердең;
Юл буенда үскән әремнәрнең
Ачыларын эчеп исердем.

Ил өстенә нинди афәт килсә,
Барысын да бергә кичердем;
Кешеләрнең кара кайгысыннан,
Якты шатлыгыннан исердем.

Рәхмәт, дөнья!
Мин гашыйкмын сиңа –
Бу яшәүдән беркем туймаган!
Һәм туймаган, айнымаган килеш
Китә алсам иде дөньядан!

Беләсең килсә...

1 **Хот-дог «кайнар эт» дип тәрҗемә ителә. Баштарак бу ризыкның атамасы шушы эт токымы белән бәйле булган.**
а) бульдог;
б) такса;
в) хотошо.

2 **Әлеге әсәрне автор 1926 елда иҗат иткән. Башта ул аны «Тугры сүз» дип исемләгән. Әмма соңыннан ул башка исем белән тарала. Әсәрнең беренче җөмләсе укучы хәтеренә аеруча уелып калган.**
а) «Тирән тамырлар»;
б) «Чаткылар»;
в) «Мөһаҗирләр».

3 **Сәгатенә 100 чакрым тизлек! Автомобильләр арасында бу рекорд беренче тапкыр 1899 елда Бельгиядә куела. Нинди машина була бу?**
а) бензин моторлы;
б) дизель ягулыклы;
в) электромобиль.

4 **Дөньяда кечкенә диңгезләр бихисап. Әмма монысы әле – дөньядагы иң сай диңгез дә. Аның иң тирән җире нибары 13,5 метр.**
а) Мәрмәр диңгез;
б) Азов диңгезе;
в) Лигурия диңгезе.

5 **Җәй көне болыннарда мәтрүшкә җыярга яратабыз. Руслар аны «душица» ди. Әмма бу фәнни атама түгел. Фәнни телдә мәтрүшкә һәм душица болай була:**
а) олеандр;
б) орегано;
в) оригами.

Җаваплар: 1) б; 2) а; 3) в; 4) б; 5) б.

Әз-мәз мәзәк

– Соңгы вакыт бөтен акчам психологка китә...
– Ни булды?
– Мин аңа өйләндем.

* * *

Быел ялыбызны кайда уткәрергә дә белгән юк. Залдамы, балкондамы, кухнядамы? Кухняда бик кыйммәт.

* * *

Тапкыр абзый пиццериягә кереп заказ ясаган да доставка машинасына утырып кайтып киткән, барыбер бер үк якка кайтасы бит!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: аргамак, әнә, залим, ли, Әлипә, тарак, им, үпкә, имән, ләм, яр, рамазан, балта, Наил, Кино, уй, ат, кар, ак, Такташ, Әмир, Нур, ки, ау, АКМ, әдәбият, латыш, аут, Арнольд, өн, та, чи, ашчы, Аяз, ар, ям, йозак.

Вертикаль: Чиккертә, Аида, прәннек, таба, По, Риза, ир, Камилә, бал, Шаян, чара, утопия, үгез, талак, Зәй, ала, әзи, Мальта, мал, Риман, адаш, яз, Анита, Нократ, чама, әкәм, Кун, ындыр, Бурнаш, Акбай, ук, Арман, ятак, Марат, Гата.

Сыерның «ире» | Мизгел | Җырчы Цой | Төкәмнең «дусты»

Ат | «... килә автомобиль»

«Ай, ..., гөлкәем»

Изүче, явыз | «ВТ» Гыйлемхановы | ... авылы көе

Ул басмаса, мин басам | Су анасы югалткан | Төз утыра, яхшы утыра | ...-том

«Чаткылар»да ... Гыйльменисасы | Тула сые | Эдгар ... | Антиниках сүзе | Әлмәндәр каргасы | Сулыш органы | Елгада ул икәү

Каршы килмәүче татар исеме | Кәрәз эчендә | ...-мим | Былтыр коралы | Урын өсте

Анда икән чикләвек! | Ураза тоту ае | Кировтан агып төшә

... Табанаков | Цой төркеме | Фикер | Арбадан алда бара

Мокамайны уйлап тапкан | Анда йомырка кыздыралар | Балалар телеканалы | ... Исламов | Башкаласы – Валетта | Дус, ахир | Түбәдән төшерәсе | Җәяннең ул берничә | Кара түгел

Фәнни фантастика жанры | ... Алиев | Әрмән исеме

Кисәкчә | ...-ат | Аңа мылтык кирәк | Исемдәш | Ул табак ашлык белән тулы | Туп китте!

Ригада яши | Калашников коралы

Аны язучылар булдыра | Шварценеггер | Гарәп хәрефе | Татар язучысы | Уянгач

Пешмәгән | Ресторатор | Ул хисне югалтырга ярамый!

Район һәм елга

Җәй алды | Майдан үлчәү берәмлеге

Зур агач табак | Мансур Гыйләҗевнең әтисе | Элек почта станциясе

Код белән була

Әгәр дә мәгәр

Әгәр дә сине бик чибәр кыз ярата, кочаклый, үбә, назлый икән, мөгаен, син – песидер.

Әгәр кирәге чыгар әле дип күп еллар саклаган әйберне бүген чыгарып атсаң, иртәгә үк кирәге чыгачак.

Әгәр көн дәвамында тырышып эшләсәң, шуны бел: нәчәлник син хәл алырга утырган вакытта килеп керәчәк.

Әгәр дә йөргән кызның синең белән очрашуда телефонын авиарежимга куя икән, белеп тор: син бу авиакомпаниянең бердәнбер пассажиры түгел.

Әгәр дә кешеләр сиңа: «Гафу, минем бу чепухага вакытым юк», – дип әйтә икән, мөгаен, аларның конкрет шушы чепухага вакытлары юктыр, башка чепухаларга алар вакыт таба.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16041 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 292

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (**420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.**)
16+